КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 12 ноябрь г.Казань № 1035

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 22 апрель, 267 нче; 2014 ел, 1 октябрь, 708 нче; 2014 ел, 14 ноябрь, 876 нчы; 2014 ел, 12 декабрь, 977 нче; 2015 ел, 8 апрель, 231 нче; 2015 ел, 19 май, 358 нче; 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы; 2015 ел, 16 июнь, 442 нче; 2015 ел, 2 ноябрь, 831 нче; 2016 ел, 24 февраль, 112 нче; 2016 ел, 15 апрель, 225 нче; 2016 ел, 8 май, 288 нче; 2016 ел, 22 июль, 498 нче; 2016 ел, 23 сентябрь, 681 нче; 2016 ел, 30 ноябрь, 884 нче; 2016 ел, 30 декабрь, 1053 нче; 2017 ел, 3 февраль, 59 нчы; 2017 ел, 26 май, 308 нче; 2017 ел, 21 июнь, 411 нче; 2017 ел, 26 июнь, 433 нче; 2017 ел, 10 октябрь, 777 нче; 2017 ел, 15 декабрь, 993 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1077 нче; 2018 ел, 19 гыйнвар, 18 нче; 2018 ел, 14 февраль, 87 нче; 2018 ел, 26 апрель, 285 нче; 2018 ел, 4 май, 318 нче; 2018 ел, 26 июнь, 519 нчы; 2018 ел, 22 сентябрь, 824 нче; 2018 ел, 24 декабрь, 1210 нчы;

2019 ел, 16 гыйнвар, 13 нче; 2019 ел, 2 апрель, 258 нче; 2019 ел, 22 июль, 612 нче; 2019 ел, 17 сентябрь, 840 нчы; 2019 ел, 28 октябрь, 965 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Ярдәмче программалар исемлеге» юлының 13 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. 2019 – 2022 елларга «Инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасын формалаштыру.»;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре</td>
<td>
Программаны финанслауның гомуми күләме 300 108 138,028 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 234 616 963,378 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 65 428 137,0 мең сум, Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидияләр – 43 943,5 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан (Тормышта авыр хәлдә калган балаларга ярдәм күрсәтү фондыннан алынган акча) – 19 094,15 мең сум.<br>
(мең сум)
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th rowspan="2">Финанслау күләме – барлыгы</th><th colspan="4">Шул исәптән</th></tr>
<tr><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th><th>федераль бюджет акчасы</th><th>Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия</th><th>бюджеттан тыш чыганаклардан акча</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>20 908 005,515</td><td>15 441 582,078</td><td>5 450 597,7</td><td>14 171,2</td><td>1 654,537</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>22 567 805,0</td><td>16 347 332,0</td><td>6 209 073,9</td><td>11 399,1</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>21 787 165,406</td><td>17 017 094,04</td><td>4 753 460,7</td><td>6 926,3</td><td>9 684,366</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>22 590 377,407</td><td>18 225 677,86</td><td>4 351 407,0</td><td>5 537,3</td><td>7 755,247</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>21 934 314,7</td><td>17 180 390,1</td><td>4 748 058,5</td><td>5 866,1</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>26 032 323,1</td><td>20 327 991,7</td><td>5 704 287,9</td><td>43,5</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>26 386 101,2</td><td>20 784 058,5</td><td>5 602 042,7</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>27 091 292,2</td><td>21 424 989,2</td><td>5 666 303,0</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>27 731 623,9</td><td>21 978 536,2</td><td>5 753 087,7</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>27 693 043,2</td><td>21 963 103,9</td><td>5 729 939,3</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>27 693 043,2</td><td>21 963 103,9</td><td>5 729 939,3</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>27 693 043,2</td><td>21 963 103,9</td><td>5 729 939,3</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>300 108 138,028</td><td>234 616 963,378</td><td>65 428 137,0</td><td>43 943,5</td><td>19 094,15</td></tr>
</table>
Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;
</td>
</tr>
</table>

«Еллар буенча бүлеп, Программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)» юлында:

«2019 елда тернәкләндерү һәм (яки) абилитацияләү чаралары гамәлгә ашырылган инвалидларның өлешен тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең

индивидуаль программасында мондый тәкъдимнәре булган Татарстан Республикасы инвалидларының гомуми санында 56,5 процентка кадәр, 2020 елда 71,9 процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «2019 елда реабилитацияләү һәм (яки) абилитацияләү чаралары гамәлгә ашырылган инвалидларның өлешен тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында мондый тәкъдимнәре булган Татарстан Республикасы инвалидларының гомуми санында 70,9 процентка кадәр, 2020 елда – 71,9 процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алыштырырга;

«2019 елда тернәкләндерү һәм (яки) абилитацияләү чаралары гамәлгә ашырылган инвалид балаларның өлешен тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында мондый тәкъдимнәре булган Татарстан Республикасы инвалид балаларының гомуми санында 69,3 процентка кадәр, 2020 елда 73,8 процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «2019 елда тернәкләндерү һәм (яки) абилитацияләү чаралары гамәлгә ашырылган инвалид балаларның өлешен тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында мондый тәкъдимнәре булган Татарстан Республикасы инвалид балаларының гомуми санында 72,8 процентка кадәр, 2020 елда – 73,8 процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алыштырырга;

«2019 елда иртәрәк ярдәм күрсәтү хезмәтеннән файдалануга мохтаҗ Татарстан Республикасы балаларының гомуми санында әлеге хезмәт күрсәтүдән файдаланган максатчан төркемдәге балалар өлешен 30 процентка кадәр, 2020 елда – 40 процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «2019 елда иртәрәк ярдәм күрсәтү хезмәтеннән файдалануга мохтаҗ Татарстан Республикасы балаларының гомуми санында әлеге хезмәт күрсәтүдән файдаланган максатчан төркемдәге балалар өлешен 35 процентка кадәр, 2020 елда – 40 процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алыштырырга;

«2019 елда Татарстан Республикасының эшкә яраклы яшьтәге инвалидларның гомуми санында эшкә яраклы яшьтәге инвалидларның эш белән тәэмин ителгән өлешен 32 процентка кадәр, 2020 елда – 50 процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «2019 елда Татарстан Республикасының эшкә яраклы яшьтәге инвалидларның гомуми санында эшкә яраклы яшьтәге инвалидларның эш белән тәэмин ителгән өлешен 40 процентка кадәр, 2020 елда – 50 процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алыштырырга;

«2019 елда инвалидларны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программаларыннан өземтәләр рәвешендәге мәгълүматлары хисап чорында Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү органнарына тапшырылган, Татарстан Республикасының эшкә урнашуга мохтаҗ инвалидларының гомуми санында эшкә урнаштырылган инвалидларның өлешен 45 процентка кадәр, 2020 елда – 60* процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «2019 елда инвалидларны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программаларыннан өземтәләр рәвешендәге мәгълүматлары хисап чорында Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү органнарына тапшырылган, Татарстан Республикасының эшкә урнашуга мохтаҗ инвалидларының гомуми санында эшкә урнаштырылган инвалидларның өлешен 50* процентка кадәр, 2020 елда – 60* процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алыштырырга;

«2019 елда Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучы инвалидларның гомуми санында эшкә урнаштырылган инвалидларның өлешен 58* процентка кадәр, 2020 елда – 75* процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «2019 елда Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте

органнарына мөрәҗәгать иткән һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучы инвалидларның гомуми санында эшкә урнаштырылган инвалидларның өлешен 70* процентка кадәр, 2020 елда – 75* процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алыштырырга;

«2019 елда беренче тапкыр инвалид дип танылган һәм Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән Татарстан Республикасы гражданнарының гомуми санында эшкә урнаштырылган инвалидларның өлешен 50 процентка кадәр, 2020 елда – 80* процентка кадәр җиткерергә» сүзләрен «2019 елда беренче тапкыр инвалид дип танылган һәм Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән Татарстан Республикасы гражданнарының гомуми санында эшкә урнаштырылган инвалидларның өлешен 70* процентка кадәр, 2020 елда – 80* процентка кадәр җиткерергә» сүзләренә алыштырырга;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 300 108 138,028 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 234 616 963,378 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 65 428 137,0 мең сум, Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидияләр – 43 943,5 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан (Тормышта авыр хәлдә калган балаларга ярдәм күрсәтү фондыннан алынган акча) – 19 094,15 мең сум.

(мең сум)

| Ел | Финанслау күләме – барлыгы | Шул исәптән | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | федераль бюджет акчасы | Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия | бюджеттан тыш чыганак-лар акчасы |
| 2014 | 20 908 005,515 | 15 441 582,078 | 5 450 597,7 | 14 171,2 | 1 654,537 |
| 2015 | 22 567 805,0 | 16 347 332,0 | 6 209 073,9 | 11 399,1 | - |
| 2016 | 21 787 165,406 | 17 017 094,04 | 4 753 460,7 | 6 926,3 | 9 684,366 |
| 2017 | 22 590 377,407 | 18 225 677,86 | 4 351 407,0 | 5 537,3 | 7 755,247 |
| 2018 | 21 934 314,7 | 17 180 390,1 | 4 748 058,5 | 5 866,1 | - |
| 2019 | 26 032 323,1 | 20 327 991,7 | 5 704 287,9 | 43,5 | - |
| 2020 | 26 386 101,2 | 20 784 058,5 | 5 602 042,7 | - | - |
| 2021 | 27 091 292,2 | 21 424 989,2 | 5 666 303,0 | - | - |
| 2022 | 27 731 623,9 | 21 978 536,2 | 5 753 087,7 | - | - |
| 2023 | 27 693 043,2 | 21 963 103,9 | 5 729 939,3 | - | - |
| 2024 | 27 693 043,2 | 21 963 103,9 | 5 729 939,3 | - | - |
| 2025 | 27 693 043,2 | 21 963 103,9 | 5 729 939,3 | - | - |
| Барлыгы | 300 108 138,028 | 234 616 963,378 | 65 428 137,0 | 43 943,5 | 19 094,15 |

Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Программаны ресурслар белән тәэмин итү буенча җентекле мәгълүмат аңа

теркәлгән 2 нче кушымтада китерелгән.»;

Программага теркәлгән 1 һәм 2 нче кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2019 – 2020 елларга «Инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасын формалаштыру» ярдәмче программасында (алга таба – Ярдәмче программа):

Ярдәмче программаның паспортын, I – V бүлекләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программа исеме | «2019 – 2020 елларга «Инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасын формалаштыру» ярдәмче программасы (алга таба – Ярдәмче программа) |
| Төбәк Программасының төп эшләнмәләре | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 17 ноябрендәге б-1662 номерлы боерыгы белән расланган 2020 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең озак вакытлы социаль-икътисадый үсеше концепциясе;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 31 августындагы б-1839 номерлы боерыгы белән расланган 2020 елга кадәрге чорга Россия Федерациясендә иртәрәк ярдәм күрсәтүне үстерү концепциясе;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 16 июлендәге б-1506 номерлы боерыгы белән расланган «Федераль инвалидлар реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасын булдыру, алып бару һәм файдалану концепциясе;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уңайлы мохит» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 29 мартындагы 363 номерлы карары белән расланган «Уңайлы мохит» Россия Федерациясе дәүләт программасы;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 10 маендагы б-893 боерыгы белән расланган 2017 – 2020 елларга инвалидларны эш белән тәэмин итү дәрәҗәсен күтәрү буенча чаралар планы;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 16 июлендәге б-1507 боерыгы белән расланган 2016 – 2020 елларга Россия Федерациясе субъектларында яшь инвалидларга һөнәри белем алганда ярдәм итү һәм алга таба эшкә урнашуда булышлык күрсәтү программаларын тормышка ашыру буенча чаралар планы;<br>2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү |

| | |
|---|---|
| | стратегиясе;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын һәм Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 23 декабрендәге 1023 номерлы карары белән расланган 2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы |
| Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы – яраштыручысы, Ярдәмче программаның төп эшләүчесе һәм үтәүчесе | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
| Ярдәмче программаның дәүләт заказчылары – Ярдәмче программаның үтәүдәшчеләре | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы;<br>Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы |
| Ярдәмче программа максаты | Татарстан Республикасында инвалидларның, шул исәптән инвалид балаларның тернәкләндерү һәм абилитацияләү хезмәтләре күрсәтү, иртәрәк ярдәм күрсәтү белән тәэмин ителеше дәрәҗәсен, шулай ук инвалидларның, шул исәптән инвалид балаларның һөнәри үсеше һәм эш белән тәэмин ителеше дәрәҗәсен (эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтүне кертеп) күтәрү |
| Ярдәмче программа бурычлары | Татарстан Республикасында инвалидларның, шул исәптән инвалид балаларның тернәкләндерү һәм абилитацияләү хезмәтләре күрсәтүгә, иртәрәк ярдәм күрсәтүгә ихтыяҗын билгеләү;<br>Татарстан Республикасында инвалидларның, шул исәптән инвалид балаларның һөнәри үсеше һәм эш белән тәэмин ителеше (эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтеп йөрүне кертеп) дәрәҗәсен арттыру өчен шартлар булдыру;<br>Татарстан Республикасында инвалидларны, шул исәптән |

| | |
|---|---|
| | инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасын оештыру, шулай ук иртәрәк ярдәм күрсәтү буенча норматив хокукый һәм методик базаны формалаштыру һәм актуаль хәлдә тоту;<br>Татарстан Республикасында инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасын, шулай ук иртәрәк ярдәм күрсәтүне үстерү өчен шартлар булдыру;<br>инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү, шулай ук иртәрәк ярдәм күрсәтү программасын тормышка ашырганда ведомствоара хезмәттәшлекне оештыру;<br>тернәкләндерү һәм абилитацияләү хезмәтләре күрсәтүдән файдалану мөмкинлеген арттыру һәм аның сыйфатын яхшырту |
| Ярдәмче программа-ның максатчан күрсәт-кечләре (индикатор-лары) | тернәкләндерүнең һәм (яки) абилитацияләүнең индивидуаль программасында тернәкләндерү һәм (яки) абилитацияләү чараларын гамәлгә ашыру турында тәкъдимнәре булган Татарстан Республикасы инвалидларының гомуми санында әлеге чаралары гамәлгә ашырылган инвалидлар өлеше;<br>тернәкләндерүнең һәм (яки) абилитацияләүнең индивидуаль программасында тернәкләндерү һәм (яки) абилитацияләү чараларын гамәлгә ашыру турында тәкъдимнәре булган Татарстан Республикасы инвалид балалаларының гомуми санында әлеге чаралары гамәлгә ашырылган инвалид балалар өлеше;<br>Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан тернәкләндерү оешмаларының гомуми санында инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү яки абилитацияләүнең төбәк системасына кертелергә тиешле тернәкләндерү оешмалары өлеше;<br>Татарстан Республикасы чыгарылыш сыйныф инвалид укучыларының гомуми санында һөнәри юнәлеш бирү эшенә җәлеп ителгән 9 нчы һәм 11 нче сыйныфларның чыгарылыш инвалид укучылары өлеше;<br>Татарстан Республикасында эшкә яраклы яшьтәге инвалидларның гомуми санында эшкә яраклы яшьтәге инвалидларның эш белән тәэмин ителгән өлеше;<br>хисап чорында инвалидларны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программаларыннан өземтәләр рәвешендә мәгълүматлары Татарстан Республи-касының халыкны эш белән тәэмин итү органнарына кертелгән эшкә урнаштыруга мохтаҗ булган Татарстан Республикасы инвалидларының гомуми санында эшкә |

| | |
|---|---|
| | урнаштырылган инвалидлар өлеше;<br>Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү органнарына мөрәҗәгать иткән һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучы инвалидларның гомуми санында эшкә урнаштырылган инвалидлар өлеше;<br>беренче тапкыр инвалид дип танылган һәм Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән Татарстан Республикасы гражданнарының гомуми санында эшкә урнаштырылган инвалидлар өлеше;<br>иртәрәк ярдәм күрсәтү хезмәтләренә мохтаҗ Татарстан Республикасы балаларының гомуми санында әлеге хезмәтләрдән файдаланган максатчан төркемдәге балалар өлеше;<br>Татарстан Республикасында иртәрәк ярдәм күрсәтү программаларына кертелгән, иртәрәк ярдәм күрсәтү хезмәтләренең сыйфатыннан канәгать булган гаиләләр өлеше;<br>Татарстан Республикасында инвалидларга, шул исәптән инвалид балаларга тернәкләндерү һәм (яки) абилитацияләү чаралары күрсәтүне тәэмин итүче, квалификация күтәрү һәм белгечләрне һөнәри яңадан әзерләү программалары буенча, шул исәптән инвалидларны тернәкләндерү һәм абилитацияләү методикаларын куллану буенча белем алган белгечләрнең Татарстан Республикасында әлеге белгечләрнең гомуми санындагы өлеше;<br>бергә яшәү белән тәэмин ителә торган инвалидларны колачлау |
| Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2019 – 2022 еллар |
| Ярдәмче программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | 2019 – 2022 елларга Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 162 677,8 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 67 553,1 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 95 124,7 мең сум.<br><br>(мең сум) |

| Ел | Акчаның гомуми күләме | Шул исәптән түбәндәгеләр акчасы | |
|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | федераль бюджет |
| 2019 | 46 160,9 | 19 387,6 | 26 773,3 |

| | |
|---|---|
| | 2020 \| 38 968,1 \| 16 366,6 \| 22 601,5<br>2021 \| 38 968,1 \| 16 366,6 \| 22 601,5<br>2022 \| 38 580,7 \| 15 432,3 \| 23 148,4<br>Барлыгы \| 162 677,8 \| 67 553,1 \| 95 124,7 |
| Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) | Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру 2020 елга түбәндәгеләрне арттырырга мөмкинлек бирәчәк:<br>тернәкләндерүнең һәм (яки) абилитацияләүнең индивидуаль программасында тернәкләндерү һәм (яки) абилитацияләү чараларын гамәлгә ашыру турында тәкъдимнәре булган Татарстан Республикасы инвалидларының гомуми санында әлеге чаралары гамәлгә ашырылган инвалидлар өлешен 71,9 процентка кадәр;<br>тернәкләндерүнең һәм (яки) абилитацияләүнең индивидуаль программасында тернәкләндерү һәм (яки) абилитацияләү чараларын гамәлгә ашыру турында тәкъдимнәре булган Татарстан Республикасы инвалид балалаларының гомуми санында әлеге чаралары гамәлгә ашырылган инвалид балалар өлешен 73,8 процентка кадәр;<br>Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан тернәкләндерү оешмаларының гомуми санында инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү яки абилитацияләүнең төбәк системасына кертелергә тиешле тернәкләндерү оешмалары өлешен 48 процентка кадәр;<br>Татарстан Республикасы чыгарылыш сыйныф инвалид укучыларының гомуми санында һөнәри юнәлеш бирү эшенә җәлеп ителгән 9 нчы һәм 11 нче сыйныфларның чыгарылыш инвалид укучылары өлешен 100 процентка кадәр;<br>Татарстан Республикасында эшкә яраклы яшьтәге инвалидларның гомуми санында эшкә яраклы яшьтәге инвалидларның эш белән тәэмин ителгән өлешен 50* процентка кадәр;<br>хисап чорында инвалидларны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программаларыннан өземтәләр рәвешендә мәгълүматлары Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү органнарына кертелгән эшкә урнаштыруга мохтаҗ булган Татарстан Республикасы инвалидларының гомуми санында эшкә урнаштырылган инвалидлар өлешен 60* процентка кадәр;<br>Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү органнарына мөрәҗәгать иткән һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучы инвалидларның гомуми санында эшкә урнаштырылган инвалидлар өлешен 75* процентка |

| | |
|---|---|
| | кадәр;<br>беренче тапкыр инвалид дип танылган һәм Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән Татарстан Республикасы гражданнарының гомуми санында эшкә урнаштырылган инвалидлар өлешен 80* процентка кадәр;<br>иртәрәк ярдәм күрсәтү хезмәтләренә мохтаҗ Татарстан Республикасы балаларының гомуми санында әлеге хезмәтләрдән файдаланган максатчан төркемдәге балалар өлешен 40 процентка кадәр;<br>Татарстан Республикасында иртәрәк ярдәм күрсәтү программаларына кертелгән, иртәрәк ярдәм күрсәтү хезмәтләренең сыйфатыннан канәгать булган гаиләләр өлешен 90 процент кадәр;<br>Татарстан Республикасында инвалидларга, шул исәптән инвалид балаларга тернәкләндерү һәм (яки) абилитацияләү чаралары күрсәтүне тәэмин итүче, квалификация күтәрү һәм белгечләрне һөнәри яңадан әзерләү программалары буенча, шул исәптән инвалидларны тернәкләндерү һәм абилитацияләү методикаларын куллану буенча белем алган белгечләрнең Татарстан Республикасында әлеге белгечләрнең гомуми санындагы өлешен 45 процентка кадәр;<br>бергә яшәү белән тәэмин ителә торган инвалидларны колачлауны 40 кешегә кадәр.<br>*Фараз күрсәткечләренә төзәтмәләр хезмәт базарындагы киеренкелекне, инвалидларны эшкә урнаштыру (эшкә урнаштырганда яшь инвалидларны озатып йөрү программаларын тормышка ашыру йомгакларын кертеп) динамикасын, инвалидларның эшкә урнашуга ихтыяҗлары, квота буенча файдалану мөмкинлеге булган эш урыннары саны турындагы статистика мәгълүматларын исәпкә алып кертелергә тиеш |

## I. Ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсе тасвирнамәсе, аның төп проблемалары һәм аларны программа ысуллары белән хәл итү кирәклеген нигезләү

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 181-ФЗ номерлы Федераль закон) Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен билгели, аның максаты – инвалидларга башка гражданнар белән беррәттән Россия Федерациясе Конституциясендә, шулай ук халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормаларында һәм Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләрендә каралган гражданлык, икътисадый, сәяси һәм башка хокукларны һәм ирекләрне тормышка ашыруда бертигез мөмкинлекләр тәэмин итү.

Бу закон белән 2012 елның 3 маендагы 46-ФЗ номерлы Федераль закон белән ратификацияләнгән Инвалидлар хокуклары турындагы конвенция нигезендә

сәламәтлек саклау, хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү, мәгариф, мәдәният эшчәнлеге, физик культура һәм спорт, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә инвалидның ихтыяҗларына күпюнәлешле бәя бирү нигезендә һәм аның тернәкләндерү потенциалын мөмкин кадәр максималь булган дәрәҗәдә тормышка ашыру максатларында тернәкләндерү һәм (яки) абилитацияләү буенча тиешле эш юнәлешләре, тернәкләндерүне яки абилитацияләүне оештыру һәм аның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре билгеләнде.

Федераль инвалидлар реестры мәгълүматлары буенча, Татарстан Республикасында 2019 елның 1 июленә инвалидлыгы булган 299 391 кеше яши (Татарстан Республикасы халкының гомуми санынннан 7,7 процент), шул исәптән 283 922 инвалид (Россия Федерациясендә республиканың өлеше – 2,52 процент) һәм 15 469 инвалид бала (Россия Федерациясендә республиканың өлеше – 2,29 процент), бу сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен махсус тормыш эшчәнлеге шартлары булдыру зарурлыгын, шулай ук инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм реабилитацияләү системасын формалаштыруны дәлилли.

Инвалидлыгы булган гражданнар саны 2018 елда 292 786 кеше тәшкил итте, 2017 елда – 295 718 кеше, 2016 елда – 300 354 кеше, 2015 елда – 316 049 кеше, 2014 елда – 318 870 кеше, 2013 елда – 320 788 кеше, шул исәптән 2018 елда – 15 277 инвалид бала, 2017 елда – 14 816 инвалид бала, 2016 елда – 14 742 инвалид бала, 2015 елда – 15 023 инвалид бала, 2014 елда – 15 125 инвалид бала, 2013 елда – 14 668 инвалид бала.

2015 – 2018 еллар өчен гражданнарга медик-социаль экспертиза үткәрү нәтиҗәләре буенча төп күрсәткечләр динамикасы һәм 2015 – 2018 еллар өчен 18 яшькә кадәрге гражданнар арасында беренчел инвалидлык буенча төп күрсәткечләр динамикасы 1 нче һәм 2 нче таблицаларда китерелде.

1 нче таблица

2015 – 2018 еллар өчен гражданнарга медик-социаль экспертиза үткәрү нәтиҗәләре буенча төп күрсәткечләр динамикасы (Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Баш медик-социаль экспертиза бюросы» федераль казна учреждениесе мәгълүматлары буенча)

| Күрсәткечләр | Еллар | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Таныкланган гражданнар – барлыгы, шулардан: | 64 002 | 60 331 | 58 040 | 20 674 |
| беренче тапкыр таныкланган | 21 675 | 19 683 | 20 227 | 20 674 |
| кабат таныкланган | 42 327 | 40 648 | 37 813 | - |
| Инвалидлар дип танылган – барлыгы, шулардан: | 51 416 | 48 322 | 47 820 | 16 215 |
| инвалид дип беренче тапкыр танылган | 19 042 | 17 014 | 17 857 | 16 215 |
| инвалид дип кабат таныкланган | 32 374 | 31 308 | 29 963 | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| Инвалидны, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программалары эшләнде | 55 216 | 51 687 | 50 989 | 50 528 |
| Беренче тапкыр инвалид дип танылган гражданнар арасында эшкә яраклы яшьтә беренчел инвалидлык дәрәҗәсе (10 мең халыкка) | 37,9 | 35,9 | 36,7 | 54,3 |

2 нче таблица

2015 – 2018 еллар өчен 18 яшькә кадәрге гражданнар арасында беренчел инвалидлык буенча төп күрсәткечләр динамикасы (Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Баш медик-социаль экспертиза бюросы» федераль казна учреждениесе мәгълүматлары буенча)

| Күрсәткечләр исеме | Еллар | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 |
| Беренче тапкыр таныкланган балалар – барлыгы, шулардан: | 2 151 | 1 991 | 1 980 | 2 134 |
| «инвалид бала» категориясе буенча инвалидлык билгеләү өчен тикшерелде | 2 149 | 1 991 | 1 980 | 2 131 |
| «Инвалид бала» категориясе буенча беренче тапкыр инвалид дип танылды | 1 754 | 1 567 | 1 642 | 1 850 |
| Балаларның беренчел инвалидлык дәрәҗәсе (10 мең балага) | 22,6 | 19,7 | 20,2 | 22,3 |

Инвалидларны тернәкләндерү өлешендә «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәреш керткән «Инвалидлар хокуклары турындагы конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә, инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру кысаларында һәм Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыкларын үтәү кысаларында тернәкләндерү һәм (яки) абилитация буенча тәкъдим ителгән чаралар комплексы каралган инвалидны, инвалид баланы тернәкләндерү һәм абилитацияләүнең индивидуаль программасын (алга таба – тернәкләндерү һәм абилитацияләүнең индивидуаль программасы) тормышка ашыру буенча медик-социаль экспертиза учреждениеләре белән үзара хезмәттәшлек итү буенча эш оештырылды.

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан бирелә торган инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын эшләү һәм тормышка ашыру тәртибен һәм аларның формаларын

раслау турында» 2017 елның 13 июнендәге 486н номерлы боерыгы белән расланган Федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан бирелә торган инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын эшләү һәм тормышка ашыру тәртибенең 14 нче пункты нигезендә, Татарстан Республикасында тернәкләндерү яки абилитацияләү чараларын үтәү өчен федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениесе түбәндәге башкарма хакимият органнарына инвалидны, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасыннан өземтә җибәрә:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына – һөнәри тернәкләндерү яки абилитацияләү, социаль тернәкләндерү яки абилитацияләү буенча;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына – медицина буенча тернәкләндерү яки абилитацияләү;

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына – физкультура-сәламәтләндерү чаралары, спорт белән шөгыльләнү буенча;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына – психологик-педагогик тернәкләндерү яки абилитацияләү буенча.

Тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын үтәү буенча Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Баш медик-социаль экспертиза бюросы» федераль казна учреждениесе белән үзара мәгълүмати хезмәттәшлекне тәэмин итү максатларында, республикада «Татарстан Республикасының инвалидлар мәгълүматлары базасы» мәгълүмат системасы эшләнде. Аңа Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм теләсә кайсы оештыру-хокукый рәвешләрдәге оешмалар тарафыннан үзләренә инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасы һәм инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасы белән йөкләнгән чараларның үтәлеше турындагы мәгълүматны федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениеләренә бирү формасын һәм тәртибен раслау турында» 2015 елның 15 октябрендәге 723н номерлы боерыгын тормышка ашыру кысаларында тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын үтәү буенча мәгълүмат кертә.

Үткәрелгән анализ күрсәткәнчә, федераль медик-социаль экспертиза бюросыннан Татарстан Республикасының үтәүчеләре итеп билгеләнгән башкарма хакимият органнарына инвалидны, инвалид баланы тернәкләндерүнең һәм абилитацияләүнең индивидуаль программасыннан өземтәләр тернәкләндерү һәм абилитацияләү юнәлешләре буенча түбәндәгечә тәшкил итә:

медицина ягыннан тернәкләндерү яки абилитацияләү буенча – 41,1 процент;

социаль тернәкләндерү яки абилитацияләү буенча – 40,6 процент;

һөнәри тернәкләндерү яки абилитацияләү буенча – 12 процент;

физкультура-сәламәтләндерү чаралары, спорт белән шөгыльләнү буенча – 1,7 процент;

психологик-педагогик тернәкләндерү яки абилитацияләү буенча – 4,6 процент.

2016 – 2018 елларда тернәкләндерүнең һәм абилитацияләүнең индивидуаль программасы буенча алынган мәгълүматлар нигезендә тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин ителгән гражданнар өлеше: инвалидлар – 88,87 процент, инвалид балалар – 89,75 процент тәшкил итте; комплекслы тернәкләндерү үзәкләрендә хезмәтләр күрсәтелә торган, тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтүгә мохтаҗ булган һәм тәэмин ителгән затлар өлеше: инвалидлар – 18 процент, инвалид балалар – 59 процент тәшкил итте.

Инвалидлар хокуклары турындагы конвенция нигезендә инвалидлар максималь бәйсезлеккә ирешү максатларында комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү хезмәтләре күрсәтүне ныгытырга һәм киңәйтергә кирәк. Инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү медицина, социаль аспектларны, мәгариф һәм эшкә урнашу мәсьәләләрен колачларга һәм инвалидларның төрле төркем затлары һәм аларның ихтыяҗлары төрле булуын исәпкә алырга тиеш. Тернәкләндерү һәм абилитацияләү мөмкин кадәр иртәрәк башланырга һәм инвалидның (инвалид баланың) ихтыяҗларын һәм көчле якларын күпюнәлешле бәяләүгә нигезләнергә, инвалидларны җирле берләшмәгә җәлеп итүгә һәм кертүгә ярдәм итәргә, инвалидлар өчен уңайлы булырга һәм аларның турыдан-туры яшәү урыннарына мөмкин кадәр якынрак булырга тиеш.

## Медицина тернәкләндерүе һәм абилитацияләве

Медицина тернәкләндерүе системада инвалидларның инвалидлылыгын профилактикалау һәм аларны тернәкләндерү буларак та аның төп өлеше булып тора. Татарстан Республикасында медицина тернәкләндерүен үстерү чаралары Медицина тернәкләндерүен үстерү программасы кысаларында тормышка ашырыла, әлеге программа Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының эксперт комиссиясе тарафыннан ике тапкыр тыңланды һәм хупланды, «Медицина тернәкләндерүен һәм шифаханә-курорт дәвалавын (шул исәптән балаларга) үстерү» ярдәмче программасы буларак «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау тармагын үстерү» дәүләт программасына кертелде.

2018 елда Татарстан Республикасында медицина тернәкләндерүе Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Медицина тернәкләндерүен оештыру тәртибе турында» 2012 елның 29 декабрендәге 1705н номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау учреждениеләрендә медицина тернәкләндерүен оештыру турында» 2013 елның 30 декабрендәге 2495 номерлы боерыгы нигезендә үткәрелде.

Татарстан Республикасында медицина тернәкләндерүе, пациентның хәле авыр булуга карап, өч этапта гамәлгә ашырыла һәм түбәндәге шартларда тәэмин ителә:

7 сәламәтлек саклау учреждениесе базасында койка егәрлеге 277 койкага исәпләнгән түбәндәге 11 стационар медицина тернәкләндерүе бүлеге, шул исәптән үзәк нерв системасы функциясе бозылган пациентлар өчен 6 бүлек (Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары өчен госпиталь» дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе, Яр Чаллы шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе, «Республика клиник неврология үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе базасында, Казан шәһәрендә – «7 нче

шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «12 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «2 нче клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе базасында – гомуми койка егәрлеге 165 койкага исәпләнгән), периферик нерв системасы һәм терәк-хәрәкәт аппараты функцияләре бозылган пациентлар өчен 4 бүлек (Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе, Яр Чаллы шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе, «Республика клиник неврология үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Нехама» шифаханәсе базасында, гомуми койка егәрлеге 92 койкага исәпләнгән), соматик авырулары булган пациентлар өчен 1 медицина тернәкләндерүе бүлеге (Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе базасында, койка егәрлеге 20 койкага исәпләнгән);

12 сәламәтлек саклау учреждениесе базасында түбәндәге 14 амбулатор медицина тернәкләндерүе бүлеге: Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе, Яр Чаллы шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе, «Республика клиник неврология үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Медицина университеты клиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «3 нче Әлмәт шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Түбән Кама үзәк район күпюнәлешле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, Казан шәһәренең «7 нче шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсенә караган Иннополис шәһәрендәге 2 нче консультатив поликлиникасы, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Отель-клиника» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте базасында; көндезге стационар койкаларының гомуми саны – 152 койка;

16 шифаханә-курорт учреждениесе:

пациентлар өчен – эшләүче гражданнарны турыдан-туры

кискен миокард инфаркты, тотрыксыз стенокардия, баш мие кан әйләнешенең кискен бозылуы, шикәр чире (диабет) буенча, йөрәккә һәм магистраль кан тамырларына операцияләр, умыртка баганасы үсешендә кимчелекләр һәм дефектлар булганда ортопедик, травматологик операцияләр, буыннарга пластик операцияләр, эндопротезлау һәм реэндопротезлау, кул-аякларга реплантацияләү ясаганнан соң, сәламәтлек саклау учреждениеләренең махсуслаштырылган бүлекләре шартларында дәвалаганнан соң турыдан-туры эшләүче гражданнар – пациентлар өчен, шулай ук риск төркемендәге йөкле хатын-кызлар өчен.

2018 елда стационар һәм амбулатор медицина тернәкләндерүе бүлекләре шартларында 23 828 кеше (2017 елда – 23 485 кеше, 2016 елда – 22 477 кеше), шифаханә-курорт учреждениеләре шартларында – өлкәннәр арасыннан 5 591 кеше (2017 елда – 5 587 кеше, 2016 елда – 5 548 кеше) дәваланды.

Татарстан Республикасында инвалид балаларга медицина ярдәме күрсәтү өч дәрәҗәле система буенча оештырылды. Беренче дәрәҗә үзәк район хастаханәләре, икенче дәрәҗә – муниципальара учреждениеләр һәм үзәкләр тарафыннан күрсәтелә.

Өченче дәрәҗәдәге учреждениегә «Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе керә.

Инвалид балаларны медицина ягыннан тәэмин итүдә иң мөһиме – бала туганга кадәр авыруларны, тумыштан һәм нәселдән килгән патологияне иртәрәк диагностикалау.

Балаларның сәламәтлеген һәм тормыш сыйфатын яхшырту максаты белән тумыштан һәм нәселдән килгән патологияне иртәрәк ачыклауга юнәлдерелгән берничә скрининг программасы тормышка ашырыла: пренаталь (бала туганга кадәр) диагностика, неонаталь һәм аудиологик скринингләр.

Бала үсешендәге бозылышларны пренаталь (бала туганга кадәр) диагностикалауны тормышка ашыру кысаларында 6 муниципальара пренаталь диагностика үзәге эшли (Казан, Яр Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт шәһәрләрендә).

Яралгы үсешендәге бозылышларны үз вакытында ачыклау максаты белән пренаталь (бала туганга кадәр) диагностика буенча эш дәвам итә. 2018 ел дәвамында пренаталь скрининг үткәрүгә 3851 йөкле хатын-кыз (92 процент) җәлеп ителде (2017 елда – 39 975, 2016 елда – 42 628). Өч ел эчендә 53 яралгыда хромосом аномалияләре (2018 елда – 162, 2017 елда – 180, 2016 елда – 188), йөрәк, үпкә, нерв системасының тумыштан кимчелекләре – 1 283 очрак (2018 елда – 417 очрак, 2017 елда – 396 очрак, 2016 елда – 470 очрак) булуы ачыкланды. Тикшерү йомгаклары буенча 459 йөклелек (2018 елда – 155 очрак, 2017 елда – 148 очрак, 2016 елда – 156 очрак) башлангыч чорларда туктатылды, бу үсешендә кимчелекләре күп булган балалар туугa юл куймаска мөмкинлек бирде.

Беренче ел яшәү дәверендә балаларга медицина ярдәме күрсәтүне яхшырту һәм фетоинфантиль югалтуларны киметү максаты белән 2018 елда сабый үлеме һәм үле туган балалар саны очракларын оператив карап тикшерү уздырылды. 2018 ел эчендә сабыйлык үлеме очракларын анализлау буенча ике оператив штаб, шул исәптән бер күчмә чара (Түбән Кама шәһәре), Татарстан Республикасында үле туган балалар очракларын анализлау буенча дүрт совет үткәрелде.

Йөкле хатын-кызларны икенче һәм өченче дәрәҗәдәге стационарларга рациональ һәм үз вакытында җибәрү маршрутын билгеләү беренче дәрәҗәдәге учреждениеләрдә урта һәм югары риск төркеменә керүче бала табулар санын киметергә мөмкинлек бирде.

2018 ел дәвамында бала табуга ярдәм күрсәтү учреждениеләрендә 45 404 бала тудырылды (медицина оешмаларының оператив мәгълүматлары буенча), шулардан беренче дәрәҗәдәге учреждениеләрдә 8,4 процент (2016 елда – 10,1, 2017 елда – 8,9), икенче дәрәҗәдәге учреждениеләрдә – 73,1 процент (2016 елда – 79,5, 2017 елда – 75,2), өченче дәрәҗәдәге учреждениеләрдә – 18,5 процент (2016 елда – 10,4, 2017 елда – 15,9) бала тудыру рөхсәт ителде. «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең перинаталь үзәгендә 8 326 бала тудырылды, 8 440 бала туды.

Аутистик спектрдагы бозылышлар хәзерге заман психиатриясе проблемасы булып тора. 2016 ел белән чагыштырганда, бу күрсәткеч 10 мең балага 5,1дән 6,7гә кадәр артты (2016 елда – 415 кеше, 2017 елда – 515 кеше, 2018 – 547 кеше). «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Академик В.М.Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә стационар балалар бүлеге 25 койкалыга һәм

көндезге 10 урынлыга үзгәртеп оештырылды, түбәндәге белгечләрнең өстәмә штат вазыйфалары билгеләнде: табиб-психиатрлар, медицина психологлары, логопедлар, социаль хезмәткәрләр, тәрбиячеләр; уңайлы булу шартлары тудырылган «Ана һәм бала» палаталарының саны арттырылды.

Казан медицина университетының фундаменталь тикшеренүләр кафедрасы белән берлектә, аутизм өлкәсендә тикшеренү эшләрен үткәрү өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте гранты алынды. Галимнәрне: психиатрлар, нейрофизиологлар, неврологлар, генетиклар, социаль эш буенча белгечләрне җәлеп итү планлаштырылды. Тикшеренүләрнең максаты – аутизм биотиплары буенча алынган мәгълүматлар нигезендә диагностика һәм абилитация үткәрү программасын эшләү.

Пациентларны социальләштерү һәм психик бозылышлары булган затларга карата җәмәгатьчелек фикерен үзгәртү максатларында, медицина ярдәме күрсәтүнең стационар һәм амбулатор дәрәҗәләрендә тернәкләндерү эше актив алып барылды. 2018 елда стационарда 6 098 пациентка (2017 елда – 5 860 кеше) һәм 105 гаиләгә – хастаханәдән тыш ярдәм дәрәҗәсендә (2017 елда – 97 кеше) психологик-социаль тернәкләндерү хезмәте күрсәтелде.

Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау учреждениеләрендә медицина тернәкләндерүенең заманча технологияләре кулланыла (хәрәкәтләрне видеоанализлау, «Траст М», Balance Treaner, Biodex Balance System SD, Biodex 4 Pro тотрыклылык терапиясе, гравитациягә каршы терапия, Pegasus 3-D-System, RT-200-SLSA, Nirvana, Amadeo HandTutor, ArmTutor, кардиопульсар һәм башкалар).

Ике патент алынды, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына караган дәвалау-профилактика учреждениеләренең гамәли эшчәнлегенә медицина тернәкләндерүе технологияләрен кертү буенча алты акт рәсмиләштерелде.

2018 елда Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау учреждениеләрендә «медицина тернәкләндерүе» юнәлеше буенча этаплап һәм өзлексез ярдәм күрсәтү системасын гамәлгә кертү, «Россия Федерациясендә медицина тернәкләндерүе системасын үстерү» пилот проектын тормышка ашыру кысаларында кадрлар әзерләү, медицина тернәкләндерүенең заманча технологияләрен (хәрәкәтләрне видеоанализлау, тотрыклылык терапиясе, гравитациягә каршы терапия һ.б.) куллану күрсәтелә торган ярдәмнең сыйфатын яхшыртырга, инвалидлык дәрәҗәсен 19,1 процентка киметергә, нерв системасы патологиясе булган пациентларның 84 процентында, терәк-хәрәкәт аппараты патологиясе булган пациентларның 93,1 процентында һәм соматик авырулары булган пациентларның 91,4 процентында көндәлек тормышта бәйсез булу дәрәҗәсен киметергә мөмкинлек бирде.

## Инвалид балаларга белем бирү һәм психологик-педагогик тернәкләндерү

2015 – 2018 елларга Татарстан Республикасының социаль сәясәтендә инклюзия концепциясен тормышка ашыру кысаларында, тулаем алганда, барлык юнәлешләр буенча мәгариф оешмасы эшчәнлеген оештыруда системалы якын килү тәэмин ителә.

Бүгенге көндә республиканың гомуми белем бирү учреждениеләрендә сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән 14 меңнән артык бала, 7 454 инвалид бала белем ала.

2018 елда мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында компенсацияләү

юнәлешендәге 972 төркем: логопедия төркеме, начар күргән, начар ишеткән, интеллекты, терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар өчен төркем оештырылды. Аларда сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән 15 670 бала тәрбияләнә. Сәламәтләндерү юнәлешендәге 217 төркемдә сәламәтләндерүгә мохтаҗ булган 4 160 бала тәрбияләнә.

Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен гомуми белем бирү махсус (коррекцияләү) оешмалары, девиант тәртипле балалар өчен оешмалар, шифаханә гомуми белем бирү оешмалары өлеше 4 процент (55 мәктәп) тәшкил итә, аларда 2 процент бала белем ала (7 964 кеше).

Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен шулай ук, аларның сәламәтлеге торышын һәм психофизик үсеш үзенчәлекләрен исәпкә ала торган барлык кирәкле шартлар тудырылган.

Белем бирү оешмаларында сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән чыгарылыш сыйныф укучылары турында мәгълүмат

| Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән чыгарылыш сыйныф укучылары саны, кеше | Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән, дәүләт йомгаклау аттестациясенә кертелгән чыгарылыш сыйныф укучылары саны, кеше | Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән, бердәм дәүләт имтиханы форматында тест тапшырган чыгарылыш сыйныф укучылары саны, кеше |
|---|---|---|
| 239 | 239 | 163 |

Белем бирү оешмалары базасында, инвалидларны тернәкләндерү чараларын гамәлгә ашыручы учреждениеләр белән тыгыз хезмәттәшлек итеп, инклюзив белем бирү үзәкләре эшли. Бу оешмаларда сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучыларга белем алу өчен махсус шартлар тудырыла.

Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучыларга һәм акыл үсеше артта калган (интеллектуаль бозылышлары булган) укучыларга башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартларын (алга таба – ФДБС) гамәлгә кертүне тәэмин итү максатларында, 2017/2018 уку елы дәвамында 158 гомуми белем бирү мәктәбе базасында сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучыларга һәм акыл үсеше артта калган (интеллектуаль бозылышлары булган) укучыларга башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартларын (алга таба – ФДБС) гамәлгә кертү тәэмин ителә. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән 984 бала башлангыч гомуми белем бирүнең җайлаштырылган төп белем бирү программалары буенча укый.

12 муниципаль районда һәм Казан шәһәр округында 22 гомуми белем бирү оешмасы (Акбусай, Апас, Әлмәт, Буа, Биектау, Түбән Кама, Нурлат, Балык Бистәсе, Сарман, Тәтеш, Теләче, Чирмешән муниципаль районнарында, Казан шәһәренең Идел буе районында) базасында 89 коррекцияләү сыйныфы оештырылды, аларда хәзерге вакытта 532 бала (начар ишеткән, сөйләме, терәк-хәрәкәт аппараты бозылган, психик үсеше тоткарланган балалар) белем ала.

151 гомуми белем бирү (массакүләм мәктәпләр) учреждениесе (Әгерҗе,

Азнакай, Алексеевск, Арча, Баулы, Бөгелмә, Алабуга, Зеленодольск, Түбән Кама, Чистай муниципаль районнарында һ.б.) базасында сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән 800дән артык бала өчен уртак уку оештырылды.

Башлангыч, төп һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен дәүләт гомуми белем бирү оешмалары челтәре тотрыклы эшли һәм үсеш ала.

52 учреждениедә 6 920 бала белем ала, шулардан 3 294 инвалид бала, шул исәптән:

398 бала (Бөгелмә, Алабуга, Яр Чаллы, Түбән Кама, Казан шәһәрләрендә) – начар ишетүче балалар өчен биш учреждениедә;

543 бала (Яр Чаллы, Казан шәһәрләрендә, Лаеш муниципаль районында)– начар күрүче балалар өчен дүрт учреждениедә;

404 бала (Әлмәт, Яр Чаллы, Түбән Кама, Казан шәһәрләрендә) – терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар өчен дүрт учреждениедә;

174 бала (Яр Чаллы, Казан шәһәрләрендә) – сөйләмнәрендә авыр тайпылышлар булган балалар өчен ике учреждениедә;

4 778 бала (республиканың 18 муниципаль районында) – интеллекты бозылган балалар өчен 37 учреждениедә.

Моннан тыш, озак дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы ике учреждениедә 200 бала (Әлмәт, Спас муниципаль районнарында) укый.

Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен учреждениеләрдә укучыларга белем бирү эшчәнлеген 1 444 укытучы гамәлгә ашыра. Дефектология белеме булган педагоглар саны – 1 249 кеше, бу һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен мәктәпләрләр һәм интернат мәктәпләр укытучыларының гомуми санынннан 86,5 процент тәшкил итә.

Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән баланы социаль мохиткә интеграцияләүнең мөһим юнәлешләреннән берсе – ул һөнәри белем алганга кадәр һөнәргә әзерләү.

Хезмәткә һәм һөнәри белем алганга кадәр әзерләү буенча уку-укыту планнарын һәм программаларны тормышка ашыру өчен барлык мәктәпләрдә һәм интернат-мәктәпләрдә тегү, слесарь, столяр остаханәләре, штукатура-буяу эшләре остаханәләре, итек эше, плитка һәм трикотаж эше, чәчәк үстерү кабинетлары булдырылды, кече медицина персоналын, эш урыннарын җыештыручылар әзерләү үткәрелде, авыл мәктәп-интернатларында авыл хуҗалыгы хезмәте кабинетлары булдырылды.

Ел саен учреждениеләрдә һөнәрләр өйрәнү эше буенча планнар төзелә, аның нигезендә гомуми белем бирү учреждениеләренең һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен өлкән сыйныфлар инвалид балаларының һөнәри ниятләре өйрәнелә; экскурсияләр, очрашулар, шәхси әңгәмәләр оештырыла.

Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен «Һөнәре буенча иң яхшы» республика һөнәри осталык конкурсы традициягә әйләнде. 2017 елда конкурста сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 35 мәктәп вәкилләре катнашты. 70тән артык катнашучы өч төп юнәлеш: «Столяр эше», «Тегү эше», «Штукатур-буяу эше» буенча иң яхшы дигән исемгә көрәште. Конкурста призлы урыннар алган җиңүчеләргә «Һөнәре буенча иң яхшы» исеме бирелде.

Чыгарылыш сыйныф укучыларының гомуми санынннан 70 проценттан артык

бала республиканың һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында укуларын дәвам итә. Аларның яртысыннан күбрәге һөнәри укытуның җайлаштырылган белем бирү программалары буенча махсуслаштырылган (коррекцияләү) төркемнәрдә укый.

Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән, урта гомуми белем алган укучыларның 45 проценты 2018 елда югары белем бирүче мәгариф оешмаларына укырга керде, шуның кадәр үк һөнәри белем бирү оешмаларында урта һөнәри белем бирү программалары буенча укуларын дәвам итте. Әлеге белем бирү оешмаларында бу категориядәге гражданнарны укыту, авыруның нозологиясенә һәм авырлыгына карап, йә махсуслаштырылган төркемнәрдә, йә интеграцияле укыту юлы белән гомуми төркемнәрдә гамәлгә ашырыла.

Гомуми белем бирү оешмаларының һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен мәктәпләрнең өлкән сыйныфлар инвалид балаларының хокукларын тормышка ашыру максатларында, һөнәри белем бирү оешмаларында түбәндәге шартлар тудырылды:

инвалид балаларны һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларны җайлаштырылган программалар буенча укыту өчен махсус төркемнәр ачылды. Хәзерге вакытта бу укыту 35 һөнәри белем бирү оешмасында оештырылды, аларның исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 17 август, б-1012 нче боерыгы белән расланды. Бу программалар буенча укучылар саны 910 кеше тәшкил итә;

«П.В.Дементьев исемендәге Казан авиация-техник көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе базасында начар ишетүче инвалидларны төп һөнәри белем бирү программалары («Мәгълүмат системалары (тармаклар буенча)», «Машина төзелеше технологиясе») буенча укыту өчен махсус төркемнәр ачылды. Укучылар саны 30 кеше тәшкил итә.

Татарстан Республикасының өч һөнәри белем бирү оешмасы аерым статус алды һәм инвалидларга һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларга инклюзив һөнәри белем бирүнең төбәк системасын үстерү буенча зур эш алып бара.

«Казан сәүдә-икътисад техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә һәм «Яр Чаллы педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә инвалидларга һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларга инклюзив урта һөнәри белем бирүнең төбәк системасына булышлык күрсәтүне тәэмин итә торган база һөнәри белем бирү оешмасы статусы бирелде.

База һөнәри белем бирү оешмасы эшчәнлегенең төп максаты – инвалидлар һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен аларның тулы кыйммәтле социальләшүенә ярдәм итә торган урта һөнәри белем бирүдән гомуми файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өчен кирәкле оештыру, методик һәм матди-техник шартлар тудыру.

«Казан төзелеш көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе Ресурс укыту-методик үзәге итеп билгеләнде.

Ресурс укыту-методик үзәге эшчәнлегенең максатчан күрсәткечләреннән берсе – яңа белем бирү программаларын (шул исәптән җайлаштырылган программаларны), инновацияле белем бирү технологияләрен, махсус белем бирү

хезмәтләре күрсәтү модельләрен (һөнәри белем бирү оешмаларында дистанцион белем бирү технологияләрен кулланышка кертеп) эшләү, апробацияләү һәм гамәлгә кертү.

«П.В.Дементьев исемендәге Казан авиация-техник көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесендә начар ишетүче затларны укыту өчен урта звено белгечләрен әзерләү юнәлешләре: «Машина төзелеше технологиясе» һәм «Мәгълүмат технологияләре» буенча махсус төркемнәр ачылды.

Югары һөнәри белем бирүче «А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе тарафыннан «Ишетү буенча мөмкинлекләре чикләнгән затларны инклюзив укыту буенча инновацияле чишелешләр комплексы» проекты (алга таба – проект) эшләнде. Проект заманча мәгълүмат технологияләре нигезендә, сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларны укыту өчен эшләнгән һәм кулланыла торган ресурсларга таянып, укыту процессында укытучыларның саңгырау һәм начар ишетүче кешеләр белән аралашу системасының программа һәм методик тәэминатын булдыруны күздә тота.

Гомуми белем бирү оешмаларының һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен мәктәпләрнең югары сыйныфлар инвалид балаларының һөнәри белем алуга хокукларын тормышка ашыру, һөнәри белем бирү оешмаларында төрле төрләрдәге авырулар белән авыручы инвалид балалар өчен махсуслаштырылган уку-укыту төркемнәрен оештыру тәҗрибәсен киңәйтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 17 август, б-1012 нче боерыгы (алга таба – боерык) белән Гомуми белем бирү оешмаларының һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен мәктәпләрнең югары сыйныф инвалид балаларының һөнәри әзерлеге һәм аларны эш белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем төзелде. Боерыкта, инвалид балалар һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар категориясен күрсәтеп, база һөнәри белем бирү оешмалары исемлеге, шулай ук әлеге категориядәге укучылар өчен укыту мөмкин булган һөнәрләр исемлеге билгеләнгән. Хәзерге вакытта расланган исемлек нигезендә Татарстан Республикасының 35 һөнәри белем бирү оешмасында сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән төрле нозологиядәге затлар өчен җайлаштырылган белем бирү программалары тормышка ашырыла, бу республиканың дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларының гомуми саныннан 41 процент тәшкил итә.

Ел саен Татарстан Республикасы икътисады өчен эшчеләр кадрлары әзерләү буенча ресурс үзәкләрен булдыру программасын тормышка ашыру кысаларында инвалидларга һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларга инклюзив белем бирүне тәэмин итә торган универсаль киртәсез мохит булдыруга аерым игътибар бирелә. Моннан тыш, инвалидларны һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларны укыту өчен белем бирү процессын оештыруны гамәлгә ашыручы республика һөнәри белем бирү оешмалары тарафыннан бюджеттан тыш акча исәбеннән түбәндәге кирәкле шартлар тудырыла:

махсус билгеләнгән парковка урыннары булдыру;

укыту-күнегүләр ясау һәм физкультура-спорт мәйданчыкларын җиһазландыру;

керү төркемендәге пандусларны урнаштыру һ.б.

2017/2018 уку елында Татарстан Республикасы территориясендә югары белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеге 145 меңнән артык студент укыган югары белем бирүче 45 мәгариф оешмасы тарафыннан гамәлгә ашырылды. Шуларның 16ысында (филиалларны исәпкә алмыйча) 599 инвалид, шул исәптән 496сы көндезге уку формасы буенча белем алды.

Инвалид студентларны укыту уку төркемнәрендә, индивидуаль уку планнары буенча башкарыла, дистанцион белем бирү технологияләрен кулланып, укыту мөмкинлеге бирелә. Мәсәлән, 2018 елда җайлаштырылган белем бирү программалары буенча 124 студент белем алды.

Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларга инклюзив белем бирү өчен шартлар тудыру һәм аларга ярдәм итүне тормышка ашыру максаты белән Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 19 декабрендәге 1600 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасында югары белем бирүче ике мәгариф оешмасы инклюзив белем бирү буенча федераль инновацияле мәйданчыклар итеп билгеләнде:

«ТИСБИ» идарә университеты» югары белем бирү учреждениесе – «Татарстан Республикасында урта һәм югары һөнәри белем бирүдә кластерлы якын килүне исәпкә алып, инклюзив белем бирү механизмнарын һәм технологияләрен эшләү һәм гамәлгә кертү» юнәлешен тормышка ашыру буенча. Университетта сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларны уңышлы укыту өчен кирәкле шартлар тудырылды, шул исәптән киртәсез инфраструктура, укытуның адаптив технологияләре, сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларны ярдәм итү структуралары (социаль-психологик үзәк, сурдотәрҗемә үзәге, кадрлар агентлыгы);

югары белем бирүче «В.Г.Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (Икътисад, идарә һәм хокук институты)» шәхси мәгариф учреждениесе – «Татарстан Республикасында инклюзив белем бирүнең күчүчән системасын булдыру һәм үстерү» юнәлеше буенча.

2011 елдан югары һөнәри белем бирүче «А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе каршында ишетү буенча сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларны һөнәри тернәкләндерү буенча Казан укыту-тикшеренү һәм методик үзәге эшли. Казан укыту-тикшеренү һәм методик үзәге тарафыннан гамәлгә ашырыла торган әзерлек юнәлешләре түбәндәгеләр:

11.03.01 Радиотехника;

11.03.02 Мәгълүмат-коммуникация технологияләре һәм элемтә системалары;

22.03.01 Материал белеме һәм материаллар технологияләре;

15.03.05 Машина төзелеше җитештерүләрен конструкторлык-технологик яктан тәэмин итү.

Инвалидлар һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларның урта һөнәри белем алу шартларын камилләштерү максаты белән, белем алучыларның яшәү урыннарына карамастан, «ТИСБИ» идарә университеты» югары белем бирү учреждениесе тарафыннан дистанцион технологияләрдән файдаланып укыту системасы – дистанцион асинхрон укыту интернет-системасы кулланышка кертелде. Дистанцион укыту «ТИСБИ» идарә университеты» югары белем бирү учреждениесе

серверында урнаштырылган стандарт уку-укыту программалары буенча махсус эшләнгән укыту комплексларыннан түләүле нигездә селектив рәвештә файдалану мөмкинлеге белән гомуми белем базаларыннан ачык рәвештә түләүсез файдалану мөмкинлеген берләштереп кулланыла.

Хезмәт базарында инвалидлыгы булган белем алучыларның, чыгарылыш сыйныф укучыларының һәм яшь белгечләрнең һөнәри процесска керүен үстерүгә булышлык күрсәтү максатларында, республикадан катнашучы инвалидлыгы булган кешеләр өчен һөнәри осталык буенча «Абилимпикс» I Илкүләм чемпионатында «Фотосурәтче-репортёр» компетенциясе буенча 1 нче урын яулагач һәм Франциядә (Бордо шәһәре) узган халыкара чемпионатта Россия җыелма командасы составында катнашу мөмкинлеге алгач, Татарстан Республикасы 2015 елдан «Абилимпикс» хәрәкәтендә катнаша.

2016 елның апрелендә инвалидлыгы булган кешеләр өчен һөнәри осталык буенча «Абилимпикс» II Илкүләм чемпионатының беренче төбәк этабы җиде компетенция («Пешекче эше», «Ландшафт дизайны», «Кирпеч салу», «Кондитерлык эше», «Буяу эше», «Программа тәэминатын эшләү», «Фотография») буенча үткәрелде. Бу компетенцияләр буенча җиңүчеләр Татарстан Республикасы командасын төзеде һәм инвалидлыгы булган кешеләр өчен һөнәри осталык буенча «Абилимпикс» II Илкүләм чемпионатында катнашу нәтиҗәләре буенча дүрт медаль яулады: ике алтын («Кирпеч салу», «Фотография» компетенцияләре буенча), ике көмеш («Кондитерлык эше», «Буяу эше»).

2017 елның октябрендә Татарстан Республикасы Президенты ярдәме белән Казан шәһәрендә «Казан төзелеш көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең һәм «Кече бизнес һәм эшмәкәрлек көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең конкурс мәйданчыкларында җиде компетенция («Кирпеч салу», «Ландшафт дизайны», «Кондитерлык эше», «Пешекче эше», «Икътисад һәм бухгалтерлык исәбе», «Буяу эше», «Фотосурәтче-репортёр») буенча «Абилимпикс» төбәк чемпионаты уздырылды. Чемпионатның ярыш чараларында Татарстан Республикасының урта һөнәри һәм югары белем бирү учреждениеләре белем алучылары арасыннан 43 конкурсант катнашты. Һөнәри юнәлеш бирү программасы кысаларында конкурс мәйданчыкларында сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен мәктәпләрдән 500дән артык белем алучы булды. Алар өчен 15 юнәлеш буенча мастер-класслар оештырылды. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан вакансияләр ярминкәсе оештырылды.

2017 елның 1 декабреннән 3 декабренә кадәр «Абилимпикс» төбәк чемпионатында җиңүчеләр арасыннан төзелгән Татарстан Республикасы җыелма командасы җиде компетенция буенча «Абилимпикс» III Илкүләм чемпионатында катнашты. Ярышлар йомгаклары буенча республика җыелма командасы «Фотосурәтче-репортёр» компетенциясе буенча бер алтын медаль һәм «Кирпеч салу», «Ландшафт дизайны», «Буяу эше» компетенцияләре буенча өч көмеш медаль яулады.

2018 елның 30 – 31 октябрендә Татарстан Республикасында инвалидлыгы булган кешеләр өчен һөнәри осталык буенча «Абилимпикс» IV Илкүләм чемпионатының төбәк этабы үткәрелде. Чемпионат ярышларында хезмәт базарында таләп ителә торган 25 компетенция (2017 елда – җиде компетенция) буенча 200дән

артык конкурсант катнашты («Кондитерлык эше», «Пешекче эше», «Икмәк-күмәч эшләнмәләреннән камыр ризыклары», «Тегүче», «Ресторан хезмәте», «Веб-дизайн», «Чәчтараш сәнгате», «Фотосурәтче-репортёр», «Робототехника» һ.б.). Җиңүчеләр Татарстан Республикасын 20 – 23 ноябрьдә Мәскәү шәһәрендә үткәрелгән «Абилимпикс» IV Илкүләм чемпионатында тәкъдим иттеләр. Ярышлар өч категория буенча үткәрелде: «мәктәп укучылары», «студентлар» һәм «белгечләр». 2018 елда «Медицина каравы», «Буяу эше», «Массажист», «Текст эшкәртү», «Пешекче эше», «Тегүче», «Агачтан кисү», «Автомобиль ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү», «Сәнгати чигү», «Икътисад һәм бухгалтерлык исәбе» кебек компетенцияләр иң күп массакүләм компетенцияләрдән булды. Татарстан Республикасын 24 компетенция буенча 31 катнашучы тәкъдим итте. Катнашу нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы гомумкоманда зачетында 3 нче урынны алды һәм индивидуаль зачетта 19 медаль яулады: «алтын» – биш компетенциядә сигез медаль («Фотосурәтче-репортёр», «Эшмәкәрлек», «Кирпеч салу», «Чәчтараш сәнгате», «Сәнәгать робототехникасы»); «көмеш» – биш компетенциядә алты медаль («Фотосурәтче-репортёр», «Сәйләндән белән үрү», «Икмәк-күмәч эшләнмәләреннән камыр ризыклары», «Ресторан сервисы», «Сәнәгать робототехникасы»); «бронза» – биш компетенциядә биш медаль («Икътисад һәм бухгалтерлык исәбе», «Ыргак белән бәйләү», «Веб-дизайн», «Ресторан сервисы»,«Агачтан кисү»).

2019 елның 23 августыннан 26 августына кадәр Татарстан Республикасында «Казан Экспо» халыкара күргәзмә үзәгенең ярышлар мәйданнарында 56 компетенция буенча «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча 45 нче дөньякүләм чемпионаты үткәрелде, аның чараларында шулай ук инвалидлыгы булган һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең оештырылган төркемнәре дә булды.

2019 елның 3 июленнән 20 сентябренә кадәр Татарстан Республикасында инвалидлар һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар арасында һөнәри осталык буенча «Абилимпикс» V Илкүләм чемпионатының төбәк этабы үткәрелде. Ярышлар Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү оешмалары базасында оештырылган 23 ярыш мәйданчыгында 46 компетенция буенча уздырылды. «Абилимпикс» республика чемпионатында 450дән артык катнашучы (14 – 65 яшьтән), 400 волонтер катнашты. Конкурсантларның эшләрен 200дән артык сертификатлаштырылган эксперт, шулардан 46 баш эксперт – эш бирүчеләр вәкилләре бәяләде.

«Абилимпикс» республика чемпионатында катнашучылар өч категория буенча төрле компетенцияләрдә ярышты: «мәктәп укучылары» (19 компетенция буенча 95 катнашучы), «студентлар» (42 компетенция буенча 220 катнашучы), «белгечләр» (28 компетенция буенча 135 катнашучы).

Республика чемпионатында җиңүчеләр 2019 елның 20 – 22 ноябрендә Мәскәү шәһәрендә узачак «Абилимпикс» V Илкүләм чемпионатында республиканы төрле категорияләр буенча 46 компетенциядә тәкъдим итәчәк.

## Адаптив физкультура һәм спорт

Татарстан Республикасында сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларның адаптив физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә зур игътибар

бирелә.

«2018 елның 31 декабре хәленә карата адаптив физик культура һәм спорт турында мәгълүматлар» дигән 3-АФК номерлы еллык статистика хисаплылыгы мәгълүматлары буенча, Татарстан Республикасында адаптив физик культура һәм спорт белән 18,3 процент яки 54 116 инвалид һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән кеше шөгыльләнә, бу республика һәм федераль программаларның максатчан күрсәткечләренә туры килә. 6 – 18 яшь категориясендәге мөмкинлекләре чикләнгән затлар өлеше – 68 процент.

Системалы рәвештә спорт белән шөгыльләнүче инвалидлар һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар саны 2007 елдан 2018 елга кадәрге чорда 18 тапкырга диярлек артты (белешмә өчен: 2007 елда – 1,1 процент, 2018 елда – 18,3 процент).

Россия Федерациясе Спорт министрлыгының һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 18 мартындагы МТ-03-07/1614/ №13-5/10/В-1781 номерлы уртак хаты нигезендә, Федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан бирелә торган инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын һәм аларның формаларын эшләү һәм тормышка ашыру тәртибен үтәү максатларында, инвалидлар өчен файдалану мөмкинлеге булган спорт корылмалары исемлеген, бу корылмаларда инвалидлар өчен физик культура һәм спорт буенча дәресләр формаларын, шулай ук инвалидлар өчен физик культура һәм спорт өлкәсендә өстәмә хезмәтләр күрсәтүдән файдалану һәм аларга йөрү кыйммән күрсәтеп, инвалидларга һәм аларның гаилә әгъзаларына инвалидларның физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү мөмкин булган урыннары турында тулы һәм җентекле мәгълүмат бирү буенча эш оештырылды.

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре белән берлектә, инвалидлар өчен барлык спорт корылмаларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү буенча даими эш алып барыла (мәгълүмат http://minsport.tatarstan.ru/rus/metodicheskie-rekomendatsii-po-sozdaniyu-adaptivni.htm сайтында), «Республика спорт-адаптация мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесе төзелде, Татарстан Республикасы шәһәрләрендә һәм районнарында «Республика спорт-адаптация мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесе каршында җайлаштырылган физик культура һәм спорт буенча спорт юнәлеше бүлекләре ачылды.

Инвалидларны физик культура һәм спорт системасына интеграцияләү өлешендә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, «Татарстан Республикасының Инвалидлар физкультура-спорт җәмгыяте» иҗтимагый оешмасы, чукраклар, сукырлар, интеллектуаль бозылышлары булган һәм терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган затлар спорты буенча спорт федерацияләре белән берлектә, ел дәвамында түбәндәге бөтенроссия һәм республика чемпионатлары һәм беренчелекләре үткәрелә:

ирекле көрәш буенча (начар ишетүчеләр спорты), грек-рим көрәше (начар ишетүчеләр спорты), хатын-кызлар көрәше (начар ишетүчеләр спорты), чаңгы узышлары (барлык категорияләрдәге инвалидлар арасында), футзал (начар

ишетүчеләр спорты), хатын-кызлар арасында голбол (сукырлар спорты), ир-атлар арасында голбол (сукырлар спорты), өстәл теннисы (төрле категорияләрдәге инвалидлар арасында), өстәл теннисы (сукырлар спорты), бочче (терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган инвалидлар арасында), җиңел атлетика (барлык категорияләрдәге инвалидлар арасында), B1 футболы (тоташ сукырлар өчен), B2+B3 футболы (начар күрүчеләр һәм күрү сәләте аз калган затлар өчен), рус шашкасы, халыкара шашка, шахмат, армспорт буенча Татарстан Республикасының 25 чемпионаты;

ирекле һәм грек-рим көрәше (чукраклар спорты), чаңгы узышлары (барлык категорияләрдәге инвалидлар арасында), кызлар һәм яшүсмерләр арасында голбол (сукырлар спорты), өстәл теннисы (барлык категорияләрдәге инвалидлар арасында), бочче (терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган инвалидлар арасында), B2+B3 футболы (начар күрүчеләр һәм күрү сәләте аз калган затлар өчен) буенча Татарстан Республикасының 16 беренчелеге;

ике комплекслы спорт чарасы: гадәттәгечә ел саен республиканың муниципаль берәмлекләрендә Инвалидлар декадасына багышланган спорт чаралары үткәрелә; «Уңайлы мохит» программасы кысаларында грек-рим көрәше (начар ишетүчеләр спорты) буенча XII ачык республика турниры үткәрелде.

Россия һәм халыкара дәрәҗәләрдә колясокаларда баскетбол буенча «Барс канатлары» Татарстан Республикасы командасы билгеле. Ярышлар Татарстан Республикасында 2009 елдан башлап ел саен үткәрелә, ә бу вакыт эчендә анда 1000нән артык кеше катнашты.

2018 елда Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең Татарстан республика оешмасы тарафыннан колясокаларда баскетбол буенча бөтенроссия ачык турнирының юбилей турниры үткәрелде, анда «Барс канатлары» командасы 4 урынны яулады. Ярышлар, гадәттәгечә, Васильево поселогындагы «УНИКС» баскетбол клубының кунакханә-спорт комплексы базасында уздырылды.

2018 елда Казан шәһәрендә 11×11 юнифайд-футбол буенча Россия Махсус Олимпиадасының бөтенроссия спартакиадасы үткәрелде, анда республика инвалид спортчылар командасы 1 урын яулады. Спартакиада җәй көне Чикаго шәһәрендә уздырылган 11×11 юнифайд-футбол буенча бөтендөнья турнирына сайлап алу этабы булды.

Халыкара һәм бөтенроссия ярышларында катнашу йомгаклары буенча безнең спортчыларыбыз төрле дәрәҗәдәге 60тан артык медаль яулады.

Татарстан Республикасы инвалид спортчылары Россия, Европа, дөньякүләм чемпионатларында, Паралимпия һәм Сурдлимпия уеннарында җиңүчеләр һәм приз алучылар булды (Зәйнуллина Марта 2018 елгы Паралимпия кышкы уеннарында терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган затлар арасында ике спорт төрендә старт йомгаклары буенча, «утырып» ярышучылар – биатлон һәм чаңгы узышларында көмеш һәм ике бронза медаль яулады. Пакин Иван 2018 елгы җәйге Сурдлимпия уеннары чемпионы булды (җиңел атлетика)).

Татарстан Республикасында спортның база паралимпия төрләре буенча Россия Федерациясенең җыелма командаларына спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы терәк оешма буларак «Спорт әзерлеге үзәге» дәүләт автоном учреждениесе билгеләнде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика балалар-яшүсмерләр спорт-адаптация мәктәбе» дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесен оештыру турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1086 нчы карары нигезендә Татарстан Республикасында сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр һәм инвалидлар өчен спорт мәктәбе ачылды. Инвалид балаларның махсус спорт әзерлеге 2015 елда ачылган «Республика спорт-адаптация мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – адаптация мәктәбе) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Хәзерге вакытта адаптация мәктәбендә начар ишетүчеләр, саңгыраулар өчен (ирекле көрәш, керлинг, йөзү, җиңел атлетика); терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган затлар өчен (академик ишү, бочча, йөзү, чаңгы узышлары, җиңел атлетика); интеллектуаль бозылышлары булган затлар (җиңел атлетика, өстәл теннисы, йөзү); начар күрүчеләр, сукырлар өчен (йөзү, җиңел атлетика) спорт төрләре буенча бүлекләр эшли. Адаптация мәктәбенең 4 бүлегендә спортның 9 төре үстерелә һәм 280гә якын укучы шөгыльләнә. Адаптация мәктәбендә 18 тренер-укытучы эшли.

Укыту-күнегүләр ясау дәресләре Казан шәһәренең түбәндәге спорт мәйданчыкларында расписание буенча үткәрелә: Үзәк стадион манежы, Спортның су төрләре сарае бассейны, «Маяк» спорт комплексы» дәүләт автоном учреждениесе, «Хезмәт резервлары» спорт-сәламәтләндерү комплексы» муниципаль автоном учреждениесе, «Баско» боз аренасы, «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 1 нче Казан интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, «4 нче Казан интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 172 нче Казан мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, «Сәламәтлеклbackgroundәренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Е.Г.Ласточкина исемендәге Казан интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе.

Спортның җайлаштырылган төрләрен үстерү өлкәсендә эш тәҗрибәсен, кадрлар потенциалын һәм 6 – 18 яшь категориясендәге шөгыльләнүче инвалид балалар һәм яшүсмерләрнең перспектив составын исәпкә алып, адаптация мәктәбе базасында икенче этап булып: 2017 елда – Яр Чаллы һәм Әлмәт шәһәрләрендә; 2018 елда – Лаеш, Мамадыш һәм Саба муниципаль районнарында бүлекләр ачылды.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында җайлаштырылган спорт өлкәсендә 155 белгеч, яки физик культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче штат хезмәткәрләренең гомуми саныннан (9 076 белгеч) 1,7 процент эшли, шулардан физик культура һәм спорт өлкәсендә – 38 белгеч, мәгариф системасында – 80 белгеч, хезмәт һәм социаль яклау өлкәсендә – 31 белгеч, иҗтимагый оешмалар өлкәсендә – 6 белгеч.

Җайлаштырылган физик культура һәм спорт өлкәсендә белгечләрнең һөнәри осталыгын яхшырту һәм кадрлар составын арттыру максатларында, 2018 елда Россия кооперация университетының Казан кооперация институтына (филиалына) караган Карьера, практика һәм эшкә урнашу үзәге базасында 520 академик сәгать күләмендә «Җайлаштырылган физик культура» өстәмә һөнәри программасы буенча белгечләрне (58 кеше) яңадан әзерләү курслары һәм 108 академик сәгать күләмендә «Җайлаштырылган физик культура» программасы буенча физик культура һәм спорт өлкәсендә белгечләрнең (14 кеше) квалификациясен күтәрү курслары уздырылды

Шулай ук инвалид балаларга һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларга физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүләр өчен уңайлы

шартлар тудыру максаты белән яшүсмерләр клубларын, яшьләр үзәкләрен җайлаштыру буенча эш алып барыла.

Татарстан Республикасында спорт объектларын җайлаштырганда инвалидларга объектлардан тамашачы буларак файдалану мөмкинлеген тәэмин итү, шулай ук спортның төрле төрләре белән индивидуаль дә һәм инвалид спортчыларны әзерләү буенча махсуслаштырылган төркемнәрдә шөгыльләнү мөмкинлеге максат итеп куелды.

Физкультура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче 6 яшьтән 18 яшькә кадәрге сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидлар өлеше 2020 елда бу категориядәге халыкның гомуми саныннан 83,5 процент тәшкил итәргә тиеш.

### Мәдәният учреждениеләрендә инвалидларны социаль-мәдәни тернәкләндерү

Инвалид балаларның өстәмә белем бирүче муниципаль мәгариф оешмаларына укырга керүе гомуми нигезләр буенча гамәлгә ашырыла. Шул ук вакытта инвалид баланы укытучы һәр уку йорты, аның авыруының үзенчәлекләрен исәпкә алып, укучыга индивидуаль якын килүне эшли.

Шулай итеп, Казан шәһәренең өстәмә белем бирүче «П.И.Чайковский исемендәге 1 нче балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе күрү буенча инвалид балаларны индивидуаль программа буенча укытуны гамәлгә ашыра. Мондый алым нәтиҗәләре булып стипендиатлар дип танылган һәм Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләре белән бүләкләнгән мөмкинлекләре чикләнгән укучыларның иҗади уңышлары тора. Хәзерге вакытта әлеге стипендиатларның берсе – «И.В.Әухәдиев исемендәге Казан музыка көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе студенты һәм бик күп бөтенроссия һәм халыкара конкурслар лауреаты булган «Незами» вокал ансамбле артисты.

Балалар сәнгать мәктәпләре мөмкинлекләре чикләнгән балалар белән эшләүдә актив катнаша. Казан шәһәрендә өстәмә белем бирү учреждениеләренең 7, 61, 76, 142, 172 нче коррекция мәктәпләре, «Сукырларны һәм начар күрүчеләрне социаль тернәкләндерү республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, «Гаврош» социаль үзәге, 4, 11 нче интернат мәктәпләр, «Апрель» һәм «Солнечный» сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләре, «Бөтенроссия Хезмәт Кызыл Байрагы ордены сукырлар җәмгыяте» гомумроссия инвалидлар иҗтимагый оешмасының Казан җирле оешмасы, «Баланы үстерү үзәге – 16 нчы балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең коррекция төркеме, Дәрвишләр поселогы интернат йорты, 2 нче Республика сабыйлар йорты белән хезмәттәшлеге җайга салынган.

2015 елдан И.Зарипов исемендәге Балалар сәнгать галереясе базасында аутист балалар өчен сынлы сәнгате буенча системалы дәресләр үткәрелә башлады. Аутист балалар өчен «Йөрәктән йөрәккә» социаль проекты (И.Зарипов исемендәге балалар сәнгать галереясе базасында мастер-класслар, күргәзмәләр, иҗади очрашулар, аутист балалар һәм аларның әти-әниләре өчен системалы дәресләр оештыру һәм үткәрү) 2016 елның декабрендә «Эт» («Собака») журналының «Социаль өлкә» номинациясендә махсус призына лаек булды.

Ведомство буйсынуындагы һөнәри белем бирү оешмалары шулай ук интернат

мәктәпләрдә, тернәкләндерү үзәкләрендә, балалар йортларында, картлар йортларында сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен даими рәвештә хәйрия концертлары үткәрә.

Татарстан Республикасында 1 960 мәдәни-ял итү тибындагы учреждение исәпләнә, аларда катнашучыларның гомуми саны 12 738 кеше булган 1 061 инклюзив клуб оешмалары; составына инвалидлар һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар кергән 506 иҗат коллективы эшли. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен файдалану мөмкинлеге булган мәдәни-ял итү учреждениеләре интернет-сайтлары – 21.

«Республика балалар китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесендә Брайль шрифты белән китаплар һәм аудиокитаплар өчен махсус фонд оештырылды, күчмә китапханә булдырылды.

Максатчан тернәкләндерү эше «Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан алып барыла. Барлык яшь төркемнәрендәге 5 меңнән артык күрү буенча инвалид, аларның гаилә әгъзалары мәгълүмати-китапханә хезмәте белән колачланган. Китапханәдә барлык хезмәтләр түләүсез күрсәтелә. «Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесеннән барлык категория инвалидлар файдаланырга мөмкин. Махсус китапханәдә сукыр кулланучыларны мәгълүмат технологияләренә (компьютер белеме курслары, Nokia смартфоннары базасында GPS-навигация, Apple сенсорлы җайланмалары, «Apple шәхси компьютеры» гомуми курсы) өзлексез өйрәтү системасы булдырылды.

Моннан тыш, күрмәүче балаларны тернәкләндерү һәм абилитацияләү бүлмәсе эшли, анда алар компьютерда шөгыльләнә, электрон лупа, тифлофлешплеер белән, шулай ук рельеф-график һәм тактиль китаплардан файдалана.

Китапханәдә тифлокомментарийлар белән кинофильмнар карау оештырылды, «сөйләшүче китаплар»ны тыңлау өчен махсуслаштырылган аппаратларны прокатка бирү базасы эшли. Китапханә нәшрият эшчәнлеге белән шөгыльләнә һәм коррекция мәктәпләрен татар һәм рус телләрендә махсус укыту әдәбияты белән, шулай ук мәктәпкәчә учреждениеләрне рельеф-график һәм тактиль китаплар белән тәэмин итә.

Балалар мәнфәгатьләрендәге гамәлләрнең республика стратегиясен тормышка ашыру кысаларында 2013 – 2017 елларда «Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Казанның 172 нче мәктәбендә күрмәүче укучыларга «Минем сайлау. Минем һөнәрем» чаралары циклын оештырды. 9 һәм 11 нче чыгарылыш сыйныфлар укучыларына «Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан эреләндерелгән һәм рельефлы-нокталы шрифт белән нәшер ителгән «Чыгарылыш сыйныф укучысы белешмәсе» бүләк ителде.

2011 – 2020 елларга «Уңайлы мохит» дәүләт программасы нигезендә инвалид балаларны өстәмә белем бирүгә җәлеп итү күрсәткече 2020 елда 50 процентка җитәргә тиеш.

2017/2018 уку елында район мәгариф оешмалары каршындагы түгәрәкләрдә һәм секцияләрдә (спорт түгәрәкләре, иҗат түгәрәкләре – музыка, рәсем ясау, биюләр

һ.б.) шөгыльләнүчеләр саны, булган мәгълүматларга караганда, 45,4 процент (2016/2017 уку елында – 27,9 процент); район мәдәният учреждениеләрендә өстәмә белем алучылар (сәнгать, музыка мәктәпләре, китапханәләр, авыл клублары һ.б.) – 20,5 процент (2016/2017 уку елында – 13,2 процент) тәшкил итте.

Татарстан Республикасының урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә инвалидларга җайлаштырылган уку программаларын эшләү буенча эш алып барыла. Шулай итеп, 2018 елда «Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллияте» дәүләт автоном мәгариф учреждениесе тарафыннан күрмәүче студентлар өчен «Инструменталь башкару», «Эстрада музыка сәнгате» белгечлеге буенча уку-укыту программасы эшләнде. Инвалидлар өчен урта һөнәри белем бирү, өстәмә һөнәри белем бирү учреждениеләрендә уку-укыту программаларын алга таба эшләү планлаштырыла.

Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр ай саен төрле мәдәни чараларга чакырыла. Казан шәһәренең «ВЕРА» инвалидларның җирле иҗтимагый оешмасы, Татарстан Республикасының ятим балаларга һәм инвалидларга ярдәм күрсәтү буенча «Наз» төбәк иҗтимагый хәйрия фонды, Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең Татар республика оешмасы, «Кече бизнес һәм эшмәкәрлек көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе (коррекция төркемнәреннән инвалидлыгы булган укучыларга), «Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең Татар республика оешмасы» – «Татарстан Республикасы Инвалидлар җәмгыяте» иҗтимагый оешмасының Казан шәһәре Совет район оешмасы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Казан шәһәре Вахитов районындагы социаль яклау бүлеге), Казан шәһәре Вахитов районының Кораллы көчләр инвалидлары җәмгыяте һ.б. кебек иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлек алып барыла.

Күрү буенча инвалидлар өчен татар һәм рус телләрендә махсус форматтагы китаплар басыла. Бу юнәлеш белән «Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе актив шөгыльләнә. 2018 елда рельеф-нокталы шрифтлы 24 китап исеме, 10 тактиль кул эшләре китабы, 47 сөйләүче китаплар, 1 эреләндерелгән шрифтлы китап нәшер ителде. Сөйләшүче китаплар «Логос» күрү буенча инвалидлар өчен Беренче интернациональ Онлайн-китапханәсендә урнаштырылды, китап укучылары Россиянең һәм якын чит илләрнең 105 төбәк махсус китапханәсеннән файдалана ала, «Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең локаль базалары өстәлгән. Басылган китаплар арасында – «Медицина массажы» белгечлеге буенча сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен медицина юнәлешендәге махсус форматтагы уку әдәбияты: 7 аудиокитап, шулар арасында «Латин теле», «Анатомия һәм кеше физиологиясе», «Шәфкать туташы эше һәм шәфкать туташы каравы», «Патология» һ.б. Брайль шрифты белән «Анатомия» һәм «Патология» дәреслекләре нәшер ителде. Моннан тыш, анатомия курсына өстәп, тактиль анатомия атласлары эшләнде. Атласлар биш юнәлешкә бүленгән: «Эчке органнар», «Мускуллар системасы», «Сөяк системасы», «Нерв системасы» һәм үз эченә рельеф-график сурәтләрне, тасвирламаларны һәм аңлатмаларны ала. Күрмәүчеләр тарафыннан сурәтләрне кабул итүне җиңеләйтү һәм алар турында төгәл һәм тулы күзаллау булдыру максатыннан һәр рәсем тифлокомментарий белән тәэмин ителгән.

«Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе»

Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесендә республика архитектура һәйкәлләренең «Тоемлы Татарстан» тактиль экспозициясе булдырылды. Моннан тыш, Татарстанның иң популяр һәм танылган истәлекле урыннары, символлары арасыннан биш 3D архитектура һәйкәлләре макеты эшләнде: Казан Кремленең Спас манарасы, Губернатор сарае, Сөембикә манарасы, Благовещение соборы, Кол Шәриф мәчете. Һәр һәйкәлгә эреләндерелгән һәм рельефлы-нокталы шрифт белән тулырак мәгълүматны үз эченә алган аерым брошюра әзерләнде.

«Татарстан 3D форматында бармак очларында» грант проекты кысаларында 2019 елда күрү буенча инвалидларның кабул итү үзенчәлекләренә җайлаштырылган 10 макет, Татарстанның иң популяр истәлекле урыннары һәм символлары арасыннан архитектура һәйкәлләренең һәм корылмаларның 3D макетын әзерләү планлаштырыла, шулай ук махсус форматтагы 10га якын басма нәшер ителәчәк.

Инвалидлар декадасын үткәрү кысаларында мәдәният учреждениеләре тарафыннан «Йөрәктән йөрәккә» хәйрия проекты чаралары оештырыла. «Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан максатчан эш алып барыла. 2018 елда 1 149 төрле мәдәни-агарту чарасы үткәрелде (575 чара, Бөтенроссия сукырлар җәмгыяте предприятиеләренең радиоузелларында рус һәм татар телләрендә 358 радиотапшыру, 216 тематик китап күргәзмәсе рәсмиләштерелде, аларның экспозицияләре сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен махсус форматта басылып чыккан басмаларны, шулай ук тактиль кабул итү ала торган рельеф-график материалларны үз эченә алган). Физик мөмкинлекләре чикләнгән сайлаучыларның хокукый культурасын күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар кысаларында «Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе һәм Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшьләр арасында алтынчы тапкыр «Без Россия гражданнары» республика иҗади конкурсы уздырылды. Конкурсның финал этабында ике шәһәр округыннан – Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләреннән һәм Татарстан Республикасының 28 муниципаль районыннан 14 яшьтән 30 яшькә кадәр физик мөмкинлекләре чикләнгә яшь гражданнар катнашты. Финал этабына барлыгы 147 эш керде.

«Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе ел саен «Доступное кино» социаль акциясен үткәрә. 2018 елда акция кысаларында халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәренә булу өчен җайлаштырылган В.И.Ленин исемендәге Мәдәният-ял итү комплексының яңартылган кинозалында күрү буенча инвалидлар өчен тифлокомментарийлар белән һәм ишетү буенча инвалидлар өчен субтитрлар белән биш инклюзив коммерциягә карамаган үз илебез фильмнары күрсәтелде.

Алишер Усмановның «Сәнгать, фән һәм спорт» хәйрия фондының начар күрүче кешеләргә «Аерым караш» ярдәм программасы кысаларында «Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе инициативасы буенча яңа проектка – начар күрүчеләр һәм күрмәүче кешеләр өчен тифлокомментарийлар белән спектакльләр күрсәтүгә старт бирелде. Китапханә хезмәткәрләре тарафыннан «Г.Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачылар театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесендә «Йорт куяны Эдвардның гаҗәеп сәяхәте» спектакленә тифлокомментарийлар һәм «Галиәскар Камал исемендәге Татар дәүләт

академия театры» дәүләт бюджет учреждениесендә «Килмешәк» спектакленә тифлокомментарийлар әзерләнде. Моннан тыш, сукырлар өчен тифлокомментарийлар белән 7 спектакль, китап күргәзмәләре, тематик әдәбият җыелмасы, сәламәт яшәү рәвеше, патриотизм, экологик белемнәр, мәгълүмати культураны үстерү тематикасына периодик басмаларга күзәтү үткәрелде (шул исәптән сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен махсуслаштырылган белем бирү учреждениеләренә барып).

Татарстан Республикасы китапханәләрендә «Халыкара физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр көне», «Инвалидларның бәйсез тормышы» һ.б. кебек китап күргәзмәләре даими үткәрелә.

«Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан тематик әдәбият сайлап алу оештырыла, сәламәт яшәү рәвеше, патриотизм, экологик белемнәр тематикасына, мәгълүмати культураны үстерү темасына әдәбият һәм вакытлы басмаларга күзәтү, шул исәптән сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен махсус белем бирү учреждениеләренә барып үткәрелә (Казан шәһәре Идел буе районының «78 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе базасында «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен «Солнечный» тернәкләндерү үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе).

«Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең мәгълүмати-библиография бүлегендә «Җәмгыятьтә инвалидлар хокуклары. Уңайлы мохиткә хокук» электрон дайджесты булдырылды, дайджест материаллары даими рәвештә яңартылып тора.

«Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан, «76 нчы Казан мәктәбе» махсус коррекция гомуми белем бирү учреждениесендә тәрбияләнүчеләрне чакырып, сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен «Ушкова йорты: тарих һәм хәзерге заман», «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм аларның ата-аналары өчен мәгълүмат көне» һ.б. экскурсияләр үткәрелә.

Мәдәният тармагы белгечләре инвалидлар өчен уңайлы булу белән бәйле мәсьәләләр буенча өзлексез инструктаж һәм укулар уза. 2018 ел йомгаклары буенча 532 китапханә хезмәткәре, 10 музей хезмәткәре, 73 театр-тамаша учреждениесе хезмәткәре укуда булдылар, шул исәптән «Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музее» дәүләт бюджет учреждениесенең ике белгече Санкт-Петербург шәһәрендәге Дәүләт дин тарихы музеенда «Үзенчәлекле балалар» музей педагогикасы программасы буенча менталь бозылышлары булган затлар белән эшләргә өйрәтелде, «Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең ике хезмәткәре Мәскәү шәһәрендә квалификация күтәрү буенча «Тифлокомментарийлау» өстәмә һөнәри программасы буенча укуда булды һәм «Югары категорияле тифлокомментатор» белгечлеге алды. «Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музее» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең бер хезмәткәре сурдотәрҗемәчеләр программасы буенча укыды. 2019 елда мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләрен сурдотәрҗемә һәм тифлотәрҗемәгә өйрәтү буенча чаралар планлаштырылды.

Инвалидларны социаль тернәкләндерү

Социаль тернәкләндерү яки абилитацияләү инвалидларны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең бер юнәлеше булып тора.

Техник җайга салу һәм метрология федераль агентлыгының 2011 елның 13 декабрендәге 912-ст номерлы боерыгы белән «Россия Федерациясенең илкүләм стандарты. Инвалидларны тернәкләндерү. Инвалидларны социаль тернәкләндерү буенча хезмәтләр күрсәтү» ГОСТ Р 54738-2011 расланды һәм гамәлгә кертелде. Бу стандарт төрле оештыру-хокукый рәвешләрдәге һәм милек рәвешләрендәге тернәкләндерү предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган инвалидларны социаль тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтүгә кагыла һәм бу төр тернәкләндерү хезмәтләренең төп төрләрен, күләмен һәм эчтәлеген билгели. Инвалидларны социаль тернәкләндерү буенча хезмәтләр күрсәтү инвалидның индивидуаль тернәкләндерү программасы нигезендә гамәлгә ашырыла һәм тормыш эшчәнлеген чикләүне киметүгә юнәлдерелгән һәм инвалидка җәмгыятькә тулысынча интеграцияләнергә мөмкинлек бирә торган чаралар комплексын үз эченә ала. Техник җайга салу һәм метрология федераль агентлыгының 2014 елның 22 августындагы 955-ст номерлы боерыгы белән «Россия Федерациясенең илкүләм стандарты. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү. Инвалидларга социаль хезмәтләр күрсәтү» ГОСТ Р 53059-2014 расланды һәм гамәлгә кертелде. Бу стандарт халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт һәм башка милек рәвешләрендәге учреждениеләр, шулай ук юридик зат төземичә генә халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнүче гражданнар тарафыннан инвалидларга, шул исәптән инвалид балаларга күрсәтелә торган социаль хезмәтләргә кагыла.

Татарстан Республикасында инвалидларга социаль тернәкләндерү буенча хезмәтләр инвалидларга социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында күрсәтелә. Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендәге мәсьәләләр 2015 елның 1 гыйнварыннан «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы һәм аларны гамәлгә ашыру кысаларында кабул ителгән законнар актлары белән җайга салына.

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль законның 14 – 17 статьялары нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү аларның тормыш шартларын начарайта торган яки начарайта алган шартлар булу сәбәпле, социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган гражданнарга күрсәтелә. Социаль хезмәт күрсәтү турындагы мәсьәләне карау өчен нигез булып граждан яки аның законлы вәкиленең социаль хезмәт күрсәтү турында язмача яки электрон формада бирелгән гаризасы яисә аның мәнфәгатьләрендә башка гражданнар һ.б. мөрәҗәгате тора. Социаль хезмәтләр социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы һәм шартнамә нигезендә күрсәтелә.

Татарстан Республикасында гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында (танудан баш тарту турында) карар кабул итү һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль

хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 ноябрь, 908 нче карары белән расланган тәртип һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 нче боерыгы белән расланган административ регламент нигезендә гражданның яшәү (тору) урыны буенча территориаль социаль яклау органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Инвалидлар һәм инвалид балалар өчен социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениесе тарафыннан бирелгән инвалидның (инвалид баланың) индивидуаль тернәкләндерү яки абилитацияләү программасы тәкъдимнәрен исәпкә алып төзелә.

Тернәкләндерү үзәкләрендә (бүлекләрендә) социаль хезмәтләр курс реабилитациясе формасында күрсәтелә. Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәтләр күрсәтү вакыты – елга ике тапкыр; инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә: социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында – ике елга бер тапкыр, ярымстационар формасында – елга ике тапкыр.

Тернәкләндерү үзәкләре эше территорияләр арасындагы принцип буенча оештырылды. Тернәкләндерү үзәкләре эшенә инновацион медик-социаль технологияләр кертелде: кинезиотерапия, кондуктив терапия ысулы, Монтессори-терапия, «PECS» ысулы, Бобат-терапия, АВА-терапия, лекотека, сенсорлы интеграцион терапия, эрготерапия, иппотерапия һ.б. Актив тернәкләндерү ысулы буларак хезмәт терапиясе кулланыла, хезмәт күнекмәләре үзләштерелә (слесарь эше, тегү эше, йортчылык, аяк киемен ремонтлау һ.б.). Учреждениеләрдә тернәкләндерүнең социомәдәни программасы күп төрле (арт-терапия, анимация эшчәнлеге, ком терапиясе, әкият терапиясе, бию терапиясе, вокал терапиясе, курчак терапиясе, коррекцион ритмика һ.б.) күрсәтелә.

Балалар һәм өлкәннәр тернәкләндерү үзәкләрендә тернәкләндерү эше ведомствоара нигездә төзелә.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре белән берлектә, инвалидлар, инвалид балалар һәм иҗтимагый оешмалар катнашында һөнәри юнәлеш бирү (һөнәр белән танышу, мультфильмнар һәм видеофильмнар күрсәтү) һәм эшкә урнаштыру мәсьәләләре буенча консультацияләр, түгәрәк өстәлләр, очрашулар үткәрелә. Предприятиеләргә, һөнәри белем бирү оешмаларына экскурсияләр үткәрелә.

Тернәкләндерү үзәкләре белгечләре медицина оешмалары белән тыгыз эшли. Медицина оешмалары белән үзара хезмәттәшлек итү кысаларында үзәкләр үз вакытында тернәкләндерү ярдәме күрсәтү кирәк булган инвалид балалары ачыкланган гаиләләр, инвалидлар турында мәгълүмат ала. Район дәвалау оешмаларының педиатрлары, терапевтлары һәм неврологлары тарафыннан инвалидларны комплекслы тернәкләндерү өчен балалар тернәкләндерү үзәкләренә җибәрү гамәлгә ашырыла. Балалар тернәкләндерү үзәкләре белгечләре тарафыннан үсешләрендә бозылышлары булган балаларга иртә ярдәм күрсәтү буенча балалар поликлиникаларының табиб-педиатрлары, балалар психиатрлары, неврологлар белән очрашулар оештырыла һәм үткәрелә.

Балалар тернәкләндерү үзәкләре инвалид балаларның белем алу мәсьәләләре буенча балалар бакчалары, гомуми белем бирү оешмалары, өстәмә белем бирү

учреждениеләре белән актив хезмәттәшлек итә (төзелгән килешүләр кысаларында). Өстәмә белем бирү учреждениеләре белән уртак мастер-классллар үткәрелә. Тернәкләндерү үзәкләре базасында һөнәри белем бирү оешмалары студентларының производство һәм диплом алды практикасын оештыру һәм үткәрү турында шартнамәләр төзелә.

2018 елда Татарстан Республикасында инвалидларны тернәкләндерү алты дәүләт инвалидларны тернәкләндерү үзәге, «Сукырлар һәм начар күрүчеләрне социаль тернәкләндерү республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән дәүләткә карамаган биш оешма тарафыннан гамәлгә ашырылды.

2018 елда дәүләт инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә 6 129 инвалид (шул исәптән 337 инвалид – «Сукырлар һәм начар күрүчеләрне социаль тернәкләндерү республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендә), дәүләткә карамаган тәэмин итүчеләрдә – 1 438 инвалид; 2017 елда – 6 949 инвалид (шул исәптән 331 инвалид – «Сукырлар һәм начар күрүчеләрне социаль тернәкләндерү республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендә), дәүләткә карамаган тәэмин итүчеләрдә – 933 инвалид реабилитация узды.

Инвалидларны тернәкләндерү үзәкләре эшчәнлегенең төп максаты – мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрдә функциональ җитешсезлекне компенсацияләү, инвалидларның җәмгыятькә максималь социаль адаптациясен һәм интеграциясен тәэмин итү, алга таба эшкә урнаштыру максаты белән һөнәри юнәлеш бирү хезмәтләре күрсәтү. Республика тернәкләндерү учреждениеләрендә инвалидлар ала торган социаль хезмәтләр: социаль-көнкүреш, социаль-медицина, социаль-психологик, социаль-педагогик, социаль-хезмәт, социаль-хокукый, социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның коммуникатив потенциалын арттыру максатларында хезмәт күрсәтүләр.

Бу хезмәтләрне күрсәтү өчен тернәкләндерү учреждениеләрендә түбәндәге белгечләр штатлары каралган:

медик-социаль тернәкләндерү бүлегендә:

инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә – невролог, терапевт, физиотерапевт, травматолог, дәвалау физик культурасы буенча табиб (инструктор), өлкән шәфкать туташы, шәфкать туташы, массаж буенча шәфкать туташы (медицина абыйсы), ләм белән дәвалау процедураларын җибәрү буенча, галокамералар, диета, процедура, палата, физиотерапия кабинеты, су белән дәвалау кабинеты, парафино-озокерит аппликацияләре буенча шәфкать туташы (хезмәт күрсәтүче белгечләрнең гомуми саны – 119 кеше);

мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә – невролог, педиатр, психиатр, физиотерапевт, офтальмолог, ортопед (травматолог-ортопед), дәвалау физик культурасы буенча табиб (инструктор), өлкән шәфкать туташы, шәфкать туташы, массаж буенча шәфкать туташы, диета, процедура, палата, физиотерапия кабинеты, су белән дәвалау кабинеты, парафино-озокерит аппликацияләре буенча шәфкать туташы (хезмәт күрсәтүче белгечләрнең гомуми саны – 210 кеше);

социаль адаптация бүлегендә:

инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә – психолог, социаль педагог, социаль эш буенча белгеч, хезмәт буенча инструктор, культоештыручы, аккомпаниатор, китапханәче (хезмәт күрсәтүче белгечләрнең гомуми саны –

61 кеше);

мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә – психолог, педагог-психолог, логопед, дефектолог, социаль педагог, социаль эш буенча белгеч, хезмәт буенча инструктор, тәрбияче, физик культура буенча инструктор, музыкаль җитәкче, концертмейстер (хезмәт күрсәтүче белгечләрнең гомуми саны – 253 кеше).

Тернәкләндерү эшендә төрле технологияләр, методикалар һәм эш алымнары кулланыла, аларның максаты – кешенең хәрәкәт итү һәм функциональ мөмкинлекләрен максималь дәрәҗәдә үстерү, ярдәм итү һәм торгызу, аның социаль-көнкүреш адаптациясен тәэмин итү, һөнәр сайлауда юнәлеш бирү.

2019 елның 1 гыйнвары хәленә карата халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләре структурасында 15 социаль-тернәкләндерү бүлеге эшли. Моннан тыш, 8 коммерциягә карамаган оешма социаль-тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтә: «Шатлык» («Радость») социаль ярдәм күрсәтү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы, «Камские зори» социаль ярдәм күрсәтү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы, «Салават Купере» («Радуга») социаль ярдәм күрсәтү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы, «Наз» («Ласка») социаль ярдәм күрсәтү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы, «Саулык» («Здоровье») социаль ярдәм күрсәтү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы, «Красноборская дубрава» социаль ярдәм күрсәтү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы, «Балкыш» («Сияние») тернәкләндерү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы, «Долголетие» социаль ярдәм күрсәтү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы.

2018 елда социаль-тернәкләндерү бүлекчәләрендә 7 598 гражданга хезмәтләр күрсәтелде, 2017 елда – 8 384 гражданга, 2016 елда – 10 065 гражданга, 2015 елда – 10 102 өлкән яшьтәге гражданга, шул исәптән инвалидларга.

Даими яшәү шартларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләрне түбәндәге учреждениеләр күрсәтә:

картлар һәм инвалидлар өчен 26 интернат йорт;

акыл үсеше артта калган балалар өчен 2 интернат йорт;

6 психоневрологик интернат.

2019 елның 1 гыйнвары хәленә карата картлар һәм инвалидлар өчен интернат йортларда 2 302 инвалидка, психоневрологик интернатларда – 2 572 инвалидка, акыл үсеше артта калган балалар өчен интернат йортларда – 236 инвалид балага хезмәт күрсәтелде. Стационар социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә яшәүче барлык инвалидларның инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерү буенча индивидуаль программалары бар, учреждениеләр администрациясе тарафыннан аларны тормышка ашыру буенча эшләр оештырыла.

Интернатлар эшчәнлегенең төп максаты – социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга яшәү өчен уңайлы шартлар тудыру. Шуңа бәйле рәвештә өлкәннәр белән эшләүнең нәтиҗәле формаларын һәм ысулларын куллану мәсьәләләренә зур игътибар бирелә, «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Республика ресурс үзәге» дәүләт казна учреждениесенең методик яктан тәэмин ителеше барышында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә интернатлар эшчәнлегенә түбәндәгеләргә юнәлдерелгән технологияләр кертелә:

өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның физик һәм психик сәламәтлеген ныгытуга (социаль туризм, скандинавия йөреше, эрготерапия, хезмәт терапиясе, сенсорлы бүлмәдә релаксация, ароматерапия, спелеотерапия (тоз бүлмәләре), спорт-сәламәтләндерү технологияләре);

мәдәни ял оештыруга (скрапбукинг, декупаж, сәнгати үрү, ялтыравыклар белән чигү, бәйләү, социаль-мәдәни анимация, арт-терапия технологияләре (китапханә терапиясе, музыка терапиясе, бию терапиясе, курчак терапиясе, әкият терапиясе, рәсем терапиясе, ком терапиясе, анималотерапия, ароматерапия, пластилин терапиясе, вокал терапиясе, кинотерапия, гарденотерапия);

башка инновацияле технологияләр (парк ритриты, хатирәләр терапиясе, «мини-музейлар» һ.б.).

Иң яхшы тәҗрибәләрне ачыклау һәм тарату максатларында ел саен картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йортлар һәм психоневрологик интернатлар арасында «Алтын көз» республика социаль программалар конкурсы үткәрелә.

Актив яшәү рәвешен формалаштыру, социаль активлыкны күтәрү максатыннан интернатларда яшәүчеләр өчен яңа форматта спорт һәм мәдәни ял чаралары оештырылды, алар арасында интернатлар клиентлары арасында шахмат һәм шашка спортын популярлаштыруга, начар гадәтләрдән һәм максатсыз вакыт үткәрүдән котылуга, интеллектуаль сәләтләрне һәм логик фикерләүне үстерүгә юнәлдерелгән республика шахмат-шашка турниры бар. Социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның иҗади активлыгын стимуллаштыру, аларны актив эшчәнлеккә һәм аралашуга, эчтәлекле ял итүгә мотивацияләү, шулай ук социаль хезмәтләр алучылар арасында талантларны ачыклау максатларында «Талантлар салават күпере» үзешчән сәнгать республика конкурсы үткәрелә. Шундый ук бәйге «Минем елларым – минем байлыгым» картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йортларда социаль хезмәтләрдән файдаланучылар өчен дә үткәрелә.

Тормыш авыр хәлдә калган балаларга ярдәм күрсәтү фондының финанс ярдәме белән тормышка ашырыла торган «Мөстәкыйль яши алам» ведомствоара программасы кысаларында интернатларда тәрбияләнүчеләрнең социаль-көнкүреш күнекмәләрен формалаштыру, беренчел хезмәт күнекмәләре булдыру, балигъ булганнан соң мөстәкыйль яшәүгә әзерлек өчен инфраструктура булдыру буенча эш алып барыла.

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль закон (14 статья) нигезендә гариза бирү системасына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасында территориаль социаль яклау органнарына социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын эшләү өчен 26 309 инвалид мөрәҗәгать итте. Шулай итеп, мөрәҗәгать итүчеләрнең гомуми санынннан 60,2 процентына тернәкләндерү үзәкләрендә инвалидларны тернәкләндерү буенча хезмәт күрсәтелде.

Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары О.Ю.Голодец тарафыннан расланган 2016 – 2020 елларга социаль өлкәдә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның халыкка социаль хезмәт күрсәтү өчен бүлеп бирелә торган бюджет акчасын этаплап ала алуын тәэмин итүгә юнәлдерелгән 2016 елның 23 маенда 3468п-П44 номерлы чаралар комплексын үтәүне оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлеш алган коммерциячел булмаган оешмаларның халыкка социаль хезмәт күрсәтүгә

бүлеп бирелә торган бюджет акчасын ала алуын оештыру буенча координация советы турында» 2016 ел, 28 июль, 524 нче карары нигезендә Татарстан Республикасында эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның халыкка социаль хезмәт күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчасын ала алуын оештыру буенча координация советы (алга таба – Координация советы) оештырылды.

Координация советы тарафыннан 2016 елның 29 августыннан Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Координация советы рәисе раслаган Эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның халыкка социаль хезмәтләр күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет чараларына этаплап үтеп керүен тәэмин итү, социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар эшчәнлегенә ярдәм итүнең төрле формаларын куллану буенча Татарстан Республикасының комплекслы чаралар планы (алга таба – Комплекслы план) эшләнде.

Комплекслы план нигезендә республикада дәүләткә карамаган оешмаларның социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәт күрсәтүгә, социаль өлкәдә хезмәт күрсәтүче дәүләткә карамаган оешмаларга ярдәм күрсәтү механизмнарыннан файдалана алуын тәэмин итү буенча, халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә норматив-хокукый базаны камилләштерү буенча даими рәвештә системалы эш алып барыла.

2019 елның 1 гыйнвары хәленә карата социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрына 1 438 инвалидка хезмәт күрсәтелгән 17 дәүләткә карамаган оешма кертелде (шулардан 10сы социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма).

Шулай итеп, Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләткә карамаган оешмаларның катнашуы өчен барлык норматив хокукый шартлар булдырылды. Нәтиҗәдә, күрелә торган чаралар мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне, шул исәптән инвалид балаларны, тернәкләндерү хезмәтләре белән колачларга мөмкинлек бирәчәк.

### Инвалид балаларга иртә ярдәм күрсәтү системасы<br>һәм аларның гаиләләрен күзәтеп тору

Иртә ярдәм күрсәтүне үстерү зарурлыгы яшәү өчен уңайлы һәм игелекле мохит булдыру, инвалид балаларга, инвалид бала статусы булмаган тереклек эшчәнлеге чикләнгән балаларга, риск төркемнәренә керүче балаларга (ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны кертеп), шулай ук социаль куркыныч хәлдә булган балаларга мәктәпкәчә белем бирү мөмкинлеген һәм сыйфатын тәэмин итү өлешендә Кеше хокукларының гомум декларациясе, Бала хокуклары турында конвенциясе нигезләмәләренә бәйле.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 31 августындагы б-1839 номерлы боерыгы белән 2020 елга кадәрге чорга Россия Федерациясендә иртә ярдәм күрсәтүне үстерү концепциясе расланды, Россия Федерациясендә 2020 елга кадәрге чорга иртә ярдәм күрсәтүне үстерү концепциясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планы расланды (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 17 декабрендәге 2723-р номерлы боерыгы).

Хәзерге вакытта иртә ярдәм күрсәтү хезмәтләре түбәндәгеләр базасында эшли:

тугыз мәктәпкәчә белем бирү оешмасы (Яр Чаллы, Казан шәһәрләрендә);

психологик-педагогик, медик-социаль хезмәт (Саба, Тәтеш муниципаль районнарында);

психологик-педагогик, медик-социаль ярдәм күрсәтү үзәкләре (Бөгелмә, Алабуга, Түбән Кама, Нурлат муниципаль районнарында, Казан, Яр Чаллы шәһәрләрендә).

Мәгариф идарәсенә караган муниципаль органнарның оператив мәгълүматлары буенча, оешмалар ел саен 1,5 яшьтән 3 яшькә кадәр 3 меңгә якын балага һәм аларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) ярдәм күрсәтә.

Иртә ярдәм хезмәте күрсәтүнең төп эшчәнлеге баланың шәхесен үстерүдә, бала белән аралашуга адекват ысуллар табуда, тәрбия бирүдә һәм укытуда, аның үсешендә тайпылышларны коррекцияләүдә ата-аналарга (законлы вәкилләренә) психологик-педагогик ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән.

Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән кече яшьтәге балаларга логопед-укытучылар, педагог-психологлар, тифлопедагоглар, сурдопедагоглар, олигофренопедагоглар, дәвалау физкультурасы инструкторлары һ.б. ярдәм күрсәтә.

Хезмәтләр күрсәтү исемлегенә индивидуаль, төркемле коррекцияләү-үстерү дәресләре, ата-аналар өчен тренинглар, балаларның психомотор һәм психосөйләм үсешен коррекцияләү, сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларны һәм кече яшьтәге инвалид балаларны үстерү һәм тәрбияләү мәсьәләләре буенча консультация бирү, булган җитешсезлекләрне коррекцияләү һ.б. керә.

Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтүгә аерым якын килү формалаштырыла, ул кече яшьтәге балалары булган гаиләләргә психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәм күрсәтү системасын булдырырга мөмкинлек бирә.

Ярдәмче программа Татарстан Республикасында белем бирү киңлегенә максатчан төркемдәге балаларны иртә ачыклау, тернәкләндерү, социаль адаптацияләү һәм интеграцияләү өчен шартлар тудыру буенча үткәрелә торган чараларның дәвамы булырга тиеш.

Үсешендә тайпылышлары булган кече яшьтәге балаларның тормыш сыйфатын яхшырту, аларның оптималь үсешен һәм җәмгыятьтә адаптацияләнүен тәэмин итү, социаль ятимлекне һәм гаилә иминлеген профилактикалау максатларында 2007 елда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасында мөмкинлекләре чикләнгән балаларны күзәтеп тору буенча иртә катнашу хезмәте концепциясе эшләнде.

Татарстан Республикасында кече яшьтәге балаларга һәм аларның гаиләләренә үз вакытында һәм комплекслы ярдәм күрсәтү мәсьәләләрен хәл итү өчен мәгариф системасында мәктәпкәчә белем бирүнең вариатив формалары булдырылды: балага уен белән ярдәм күрсәтү үзәкләре, консультация бирү пунктлары, лекотекалар һәм гаилә шартларында тәрбияләнүче балалар (ата-аналар, законлы вәкилләр) өчен иртә ярдәм күрсәтү хезмәте.

2008 елның гыйнварыннан Казан шәһәренең «9 нчы балалар шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең пилот учреждениесе базасында иртә булышлык күрсәтү кабинеты ачылды. 2009 елдан Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан «2009 – 2011 елларда Татарстан Республикасында үсешендә бозылышлары булган һәм мөмкинлекләре чикләнгән кече яшьтәге балаларны күзәтеп тору буенча иртә

катнашу» озак вакытлы максатчан программасы тормышка ашырылды. Аны тормышка ашыру кысаларында 2009 елдан 2014 елга кадәр Яр Чаллы шәһәренең «2 нче балалар шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Бөгелмә үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Чистай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Зәй үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, Яр Чаллы шәһәренең «Кама балалар медицина үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең балалар поликлиникалары базасында иртә катнашу кабинетлары оештырылды.

Бу юнәлеш буенча эшнең дәвамы – «2012 – 2014 елларга үсешендә һәм сәламәтлегендә тайпылышлары булган балаларны тәрбияләүче гаиләләргә яшәү урыны буенча ведомствоара патронаж хезмәте күрсәтү системасын формалаштыруның комплекслы программасы» озак вакытлы максатчан программасын тормышка ашыру.

Иртә ярдәм күрсәтү технологияләре «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, Казан шәһәренең «8 нче балалар шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, Казан шәһәренең «Республика махсуслаштырылган сабыйлар йорты» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, Казан шәһәренең «Республика балалар психоневрология шифаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе базасында тормышка ашырыла.

Ел саен сәламәтлек саклау оешмаларында, иртә катнашу технологияләрен кулланып, 0 яшьтән 3 яшькә кадәрге 3 418 бала комплекслы тернәкләндерү һәм диагностика үтә.

Татарстан Республикасында беренчел балалар инвалидлыгы структурасында авырулар класслары буенча 37 процент яман шеш авырулары, 29,7 процент – психик бозылышлары һәм үз-үзен тоту бозылышлары, 17,1 процент – нерв системасы авырулары, 14,4 процент – тумыштан килгән аномалияләр (үсеш кимчелекләре), 4,2% – күрү бозылу, 3,7 процент – ишетү бозылу һ.б. тәшкил итте

Татарстан Республикасында инвалид балаларны социаль тернәкләндерүне мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен 12 тернәкләндерү үзәге гамәлгә ашыра.

2018 елда мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен дәүләт тернәкләндерү үзәкләрендә 6 120 инвалид бала, дәүләткә карамаган тәэмин итүчеләрдә – 2 208 инвалид бала; 2017 елда – 5 922 инвалид бала, дәүләткә карамаган тәэмин итүчеләрдә – 1 741 инвалид бала тернәкләндерелде.

Тулаем алганда, республика буенча дәүләт тернәкләндерү үзәкләрендә һәм дәүләткә карамаган тәэмин итүчеләрдә тернәкләндерү хезмәтләре соңгы өч елда 13,4 процентка (2016 елда – 7 030 кеше, 2017 елда – 7 823 кеше, 2018 елда – 8 328 кеше) артты.

2018 елда дәүләт тернәкләндерү үзәкләрендә төрле яшь категорияләрендәге инвалид балалар тернәкләндерелде: 0 яшьтән 3 яшькә кадәр – 821 кеше, 4 яшьтән 7 яшькә кадәр – 1 688 кеше, 8 яшьтән 14 яшькә кадәр – 2 606 кеше һәм 15 яшь һәм аннан зурраклар арасында – 1 005 кеше.

2018 елда хезмәт күрсәтелгән балаларның гомуми санынннан 4 яшьтән алып

7 яшькә кадәр мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына 1 102 бала йөрми (18 процент), 7 яшьтән 18 яшькә кадәр 428 кеше өйдә белем ала һәм 138 бала оештырылмаган (мәктәпкә йөрми) (2,3 процент).

2018 елда тернәкләндерү үзәкләре тарафыннан 45 ятим балага, опекага алынган 300 балага һәм тулы булмаган гаиләдә тәрбияләнүче 843 балага хезмәт күрсәтелде.

Үзәкләрдә тернәкләндерү узган балаларның күбесе үзәк нерв системасы авырулары булган балалар – 42 процент (шул исәптән аутистик спектр бозылышы белән – 5,3 процент); терәк-хәрәкәт аппараты зарарлану белән – 28,7 процент, шуның 6,5 проценты коляскадагы инвалидлар; соматик авырулар белән – 23,3 процент; күрү буенча инвалидлар – 4,28 процент, ишетү буенча инвалидлар – 2,83 процент.

Тернәкләндерү үзәкләре эше территория арасындагы принцип буенча оештырылды. Тернәкләндерү үзәкләре эшенә инновацияле медик-социаль технологияләр кертелде: кинезиотерапия, кондуктив терапия ысулы, Монтессори-терапия, «PECS» ысулы, Бобат-терапия, АВА-терапия, лекотека, сенсорлы интеграцион терапия, эрготерапия, иппотерапия һ.б. Актив тернәкләндерү ысулы буларак хезмәт терапиясе кулланыла, хезмәт күнекмәләре үзләштерелә (слесарь эше, тегү эше, хуҗалык алып бару, аяк киемен ремонтлау һ.б.). Учреждениеләрдә тернәкләндерүнең социаль-мәдәни программасы тәкъдим ителгән (арт-терапия, анимация эшчәнлеге, ком терапиясе, әкият терапиясе, бию терапиясе, вокал терапиясе, курчак терапиясе, коррекция ритмикасы һ.б.).

Хәрәкәт тайпылышлары булган инвалид балалар белән эшләүдә тернәкләндерүнең техник чараларын куллануга урын бирелә. Тернәкләндерү «Атлант» нейроортопедик тернәкләндерү пневмокостюмын, Гросс аппаратларын, төрле типтагы ходунки, вертикализаторлар, ортопедик велосипедлар, тренажерлар кулланып үткәрелә.

Тернәкләндерү үзәкләрендә үткәрелә торган чараларның нәтиҗәлелеге күзәтелә. Шулай итеп, 2018 ел нәтиҗәләре буенча инвалид баланың 43 проценты хәрәкәт итү функцияләрен яхшыртты, 65 процент – коммуникацион күнекмәләрен арттырды, 68 процент – үз-үзенә хезмәт күрсәтү, социаль-көнкүреш адаптация күнекмәләренә өйрәнде, 72 процент – һөнәри юнәлеш бирүче чаралары алды, 80 процент – социаль-көнкүреш адаптациясе күнекмәләрен алды.

Үткәрелә торган тернәкләндерү чаралары инвалид балаларның социальләшүенә һәм адаптацияләнүенә уңай йогынты ясый, аларны алга таба да уңышлы тормышка чыгаруда ярдәм итә.

Бүген республикада барлыкка килә торган вәзгыятькә анализ ясап, инвалидлыгы булган кешеләрне, инвалид балаларны иҗтимагый тормышка тулысынча җәлеп итү буенча бурычларны хәл итү өчен инвалидларны тернәкләндерүне камилләштерүгә, белем алуда ярдәм күрсәтүгә, һөнәри юнәлеш бирү һәм эшкә урнашуга юнәлдереләчәк, шулай ук инвалидларның иҗтимагый, мәгариф, мәдәни һәм спорт тормышына интеграцияләнүенә һәм аларның уңышлы тормышка ашырылуына ярдәм итәчәк комплекслы тернәкләндерү программасын эшләргә кирәк.

Бу программаны тормышка ашыруда барлык тармак белгечләре, башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук иҗтимагый оешмалар,

волонтерлык хәрәкәтләре һәм ата-аналар берләшмәсе катнашырга тиеш. Бу юнәлештә беренче адым дип 2018 елда инвалид балалар һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен тернәкләндерү үзәкләрендә узган «Бергә булдырабыз» республика социаль проектын тормышка ашыруны атарга мөмкин. Әлеге проект «Бердәм Россия» партиясенең «Ныклы гаилә» федераль проекты кысаларында тормышка ашырылды һәм инвалид балалар һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен аларның көнкүреш, хезмәт һәм физик тәрбия алуына, белем һәм күнекмәләр алуына, шулай ук мөстәкыйль тормыш һәм үз-үзен билгеләү өчен кирәкле һөнәри юнәлеш бирүгә этәрүче уңайлы шартлар булдыруга юнәлдерелде. Әлеге проектның төп юнәлешләре түбәндәгеләр:

«Минем сәләтем – минем мөмкинлекләр» юнәлеше. Бу юнәлеш буенча эшнең төп максаты булып инвалид балаларда көнкүреш күнекмәләрен формалаштыру, аларны һөнәрләр дөньясы белән таныштыру, аларга башлангыч хезмәт күнекмәләрен үстерү, аларның һөнәри ориентациясен оештыру, балаларга һәм аларның ата-аналарына мәктәпне тәмамлаганнан соң балалар кая укырга бара алачагы турында мәгълүмат җиткерү тора. Хәзерге вакытта мөмкинлекләре чикләнгән балаларны һөнәри әзерләү мәсьәләләренә зур игътибар бирелә. Россия Федерациясе Президенты В.В.Путин «Россия – мөмкинлекләр иле» проектларында җиңүчеләр белән очрашуда Россиядә мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен һөнәри әзерлек үзәкләре булдыруның мөһимлеген билгеләп үтте. Шуңа күрә, проект кысаларында, Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт учреждениеләре, шулай ук мәгариф учреждениеләре һәм предприятиеләр белән берлектә, һәр үзәктә балаларны һәм яшүсмерләрне һөнәрләр дөньясы белән таныштыруга, һөнәри үзбилгеләнешкә, һөнәр сайлауга юнәлдерелгән һөнәри юнәлеш бирүче чаралар комплексы эшләнде.

Бу юнәлеш кысаларында шулай ук өч яшькә кадәрге балаларга иртә ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән яңа технологияләрне апробацияләү һәм гамәлгә кертүгә дә игътибар бирелде. Биредә дә шулай ук сәламәтлек саклау, социаль хезмәт күрсәтү һәм мәгариф белгечләренең комплекслы ведомствоара эше кирәк булачак. Мондый ведомствоара эшне апробацияләүдә Тормышта авыр хәлдә калган балаларга ярдәм күрсәтү фондының грант проектларында катнашу да яхшы мөмкинлек булырга мөмкин.

Комплекслы тернәкләндерү яки абилитацияләүдә катнашучы оешмалар эшчәнлегенә иртә ярдәм күрсәтүнең алдынгы IT-технологияләрен гамәлгә кертү, шулай ук аларның ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлеген тәэмин итү дә мөһим фактор булып тора;

«Социаль инклюзия» юнәлеше. Бу юнәлешнең төп максаты – үз яшьтәшләре белән уртак чаралар үткәрү, волонтерларны төрле чаралар үткәрүгә җәлеп итү, шулай ук инвалид балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләренә йөреп, үз сәләтләрен үстерүгә мөмкинлек бирү.

Тулаем алганда, Татарстан Республикасы буенча индикаторларга ирешүгә карамастан, инвалид балаларга өстәмә белем бирү һәм физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә зур игътибар бирергә кирәк булган берничә муниципаль берәмлек бар, башкарма хакимият органнарына мәгариф, мәдәният, физик культура һәм спорт өлкәсендә өстәмә белем бирү буенча инвалид балаларны җәлеп итү, ата-аналарга балаларны төрле түгәрәкләргә һәм секцияләргә җыю мөмкинлеге турында

мәгълүмат бирү эшен көчәйтергә кирәк;

«Нык гаилә – бәхетле балачак» юнәлеше очраклы гына сайланмаган. Гаиләдә инвалид бала барлыкка килү – аның бөтен мохите өчен шактый авыр сынау.

Ата-аналар, бер яктан, үз балалары өчен белем бирү һәм тәрбия бирү ысулларын сайлауда кыенлыклар, икенче яктан – үсешендә һәм сәламәтлегенең мөмкинлекләре чикләнгән бала туу һәм гаиләнең тормыш рәвешен, аны бала карау мәсьәләләренә буйсындырып, бөтенләй үзгәртү кирәклеге белән бәйле психологик проблемалар кичерә.

Иртә ярдәм күрсәтелгән гаиләләрнең 90 проценты күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатыннан канәгать.

Гаиләдә сыйфатлы үзгәрешләр түбәндәгеләрдә чагыла:

психологик дәрәҗәдә, киеренкелек аркасында гаиләдә мөнәсәбәтләр бозылганда, өстәмә кыенлыклар һәм низаглар килеп чыга, бу гаилә таркалуга китерергә мөмкин;

социаль дәрәҗәдә, чөнки гаилә үз эченә йомыла, аз аралашучанга әверелә, туганнары белән аралашудан баш тарту очраклары да була.

Шуңа күрә бу юнәлеш кысаларында шулай ук ата-аналарга психологик ярдәм күрсәтүгә, аларны ял итү эшчәнлегенә җәлеп итүгә дә игътибар бирелде. Һәр гаилә тормышында мөһим мәсьәлә булып эш белән тәэмин ителү проблемасы тора. Ата-аналарны, бигрәк тә авыл җирендә, алынган белемгә туры китереп, эшкә урнаштыру проблемасы бар. Әмма максатчан төркемдәге балалары булган гаиләләрнең күбесенә, объектив сәбәпләр аркасында, эшкә урнашуы кыен, чөнки мондый гаиләләрдә балаларны карау вакытның күп өлешен алып тора, аларга ирекле эш графигы кирәк. Шулай итеп, эш бирүчеләр тарафыннан тәкъдим ителгән вакансияләр инвалид балалары булган гаиләләрнең шәхси ихтыяҗларын һәр вакытта да исәпкә алмый.

Гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү принципларын эшләү кысаларында һәр муниципаль берәмлектә социаль хезмәт күрсәтү үзәкләре базасында «Тегү эше», «Чәчтараш эше», «Компьютер белеме», «Бакчачылык» юнәлешләре буенча хезмәт тернәкләндерүе кабинетлары булдырылды. Аларны ата-аналар тарафыннан хезмәт күнекмәләре алу өчен куллану мөмкин. Чараларны гамәлгә ашыру гаиләнең үз ресурсларын активлаштырырга, авылда да, шәһәрдә дә гаиләнең тормыш сыйфатын яхшыртырга мөмкинлек бирәчәк.

Инвалид балалар тәрбияләүче гаиләләрнең ихтыяҗларын анализлау һәм бәяләү нәтиҗәләре буенча, гаиләләрнең түбәндәге ярдәмгә мохтаҗ булуы ачыкланды:

психологик хезмәтләр алуда (сораштырылганнарның 44 проценты);

шифаханә-курорт дәвалавы алуда (42,3 процент);

техник тернәкләндерү чаралары алуда (26 процент);

педагогик хезмәтләр һәм белем алуда (16 процент);

ял чараларында катнашуда (15 процент);

юридик хезмәтләр алуда (12 процент);

хәйрия, финанс ярдәме, дарулар алуда ярдәм һәм башкалар. (12 процент);

ата-аналарны эшкә урнаштыруда һәм үзмәшгульлеге буенча (6 процент).

Тернәкләндерү яки абилитацияләү мәсьәләләрен хәл итүгә комплекслы якын килеп, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекнең нәтиҗәлелеген һәм оперативлыгын арттырып, кирәкле ярдәм һәм күрсәтелгән ихтыяҗлар буенча ярдәм күрсәтергә мөмкин.

Тернәкләндерү үзәкләренә 18 яшькә кадәрге инвалид балалар һәм 3 яшькә кадәрге инвалидлыклары булмаган мөмкинлекләре чикләнгән балалар хезмәт күрсәтүгә алына.

Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләре «Иртә катнашу» программасы буенча кече яшьтәге балаларга ярдәм күрсәтә. Үзәкләр белгечләре семинарларга, конференцияләргә бара, Санкт-Петербург шәһәрендә Иртә катнашу институтында, Мәскәү шәһәрендә Дәвалау педагогикасы үзәгендә стажировка уза.

Иртә катнашу программаларының үзенчәлеге – иртә башлау гына түгел, ә гаиләгә игътибар бирү дә. Иртә катнашу буенча белгечләр командасының төп бурычы – ата-аналарны өй шартларында бала белән шөгыльләнергә өйрәтү, аның өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашуын һәм коммуникациясен җайга салу, әйләнә-тирә мохиткә җайлаштыру, үстерүче дәресләр программасын сайлау һәм гаилә әгъзаларына психологик һәм ресурслы ярдәм күрсәтү.

2018 елда сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен дәүләт тернәкләндерү үзәкләрендә сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән 647 бала тернәкләндерү курсы узды (2015 елга карата үсеш – 18 процент), дәүләткә карамаган социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләрдә –сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән 182 бала; 2017 елда сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен дәүләт тернәкләндерү үзәкләрендә сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән 623 бала, Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына кертелгән дәүләткә карамаган социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләрдә – сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән 160 бала; 2016 елда сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен дәүләт тернәкләндерү үзәкләрендә – сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән 419 бала (2015 елга карата үсеш – 18 процент), дәүләткә карамаган социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләрдә –сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән 125 бала.

2009 елдан 2014 елга кадәр Тормышта авыр хәлдә калган балаларга ярдәм күрсәтү фондын финанслауда республикада түбәндәге озак вакытлы республика максатчан программалары тормышка ашырылды:

«Инвалид тормыш стилен яхшырту һәм профилактикалау максатларында инвалид балаларны һәм аларның гаиләләрен яшәү урыны буенча социаль тормышка актив кертү программасы»;

«2012 – 2014 елларга үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлары булган балалар тәрбияләүче гаиләләргә яшәү урыны буенча ведомствоара патронаж хезмәте системасын формалаштыруның комплексны программасы».

Берничә ел дәвамында проект эшчәнлеге кысаларында республикада «Өйдә визит ясау» технологиясе эшкәртелде.

Бу программалар кысаларында «Өйдә визит ясау» технологиясе республиканың 18 муниципаль берәмлегендә сыналды. Социаль хезмәт күрсәтүнең пилот учреждениеләре базасында ата-аналар өчен консультация-укыту кабинетлары, лекотекалар оештырылды, методик материаллар һәм кирәкле җиһазлар әзерләнде (белешмәлек һәм укыту пакетлары, координаторлар сумкалары).

Бу технология инвалид балаларны даими караучы гражданнарга өйдә социаль хезмәтләр күрсәтү нигезенә алынды.

2018 елда өйдә социаль хезмәт күрсәтүне рәсмиләштергән гаиләләр саны

724 тәшкил итте (бу категориядәге гаиләләрнең гомуми санынннан 44,3 процент), аларда 739 инвалид бала тәрбияләнә, 2017 елда – 718 (бу категориядәге гаиләләрнең гомуми санынннан 44,5 процент), аларда 724 инвалид бала тәрбияләнә, 2016 елда – 747 (бу категориядәге гаиләләрнең гомуми санынннан 44,3 процент), аларда 755 инвалид бала тәрбияләнә.

Социаль хезмәтләр күрсәткәндә һәм социаль тәэмин иткәндә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының ведомствоара хезмәттәшлек итү тәртибе (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 14 ноябрь, 866 нчы карары) һәм Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасы вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының ведомствоара хезмәттәшлек итү регламенты (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 25 ноябрь, 907 нче карары) расланды.

### Һөнәри тернәкләндерү һәм эшкә урнашу процессын оештыру

Хәзерге вакытта Россия Федерациясендә, шулай ук Татарстан Республикасында да дәүләт хакимияте органнарының игътибар үзәгендә инвалидларның аларны җәмгыятькә интеграцияләүгә һәм тернәкләндерүгә хокукларын гамәлгә ашыру, инвалидларның һөнәри үсеше һәм эш белән тәэмин ителеше дәрәҗәсен арттыру өчен шартлар булдыру мәсьәләләре тора.

Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә һөнәри белем бирүне нәтиҗәле оештыру һәм аларны алга таба эшкә урнаштыру мәсьәләләре актуаль булып тора, шуңа бәйле рәвештә чаралар күрү кирәк булачак, шул исәптән түбәндәгеләр буенча:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 16 июлендәге б-1507 номерлы боерыгы белән расланган 2016 – 2020 елларга Россия Федерациясе субъектларында яшь инвалидлар һөнәри белем алганда һәм алга таба эшкә урнаштырганда аларны озатып йөрү программаларын тормышка ашыру буенча чаралар планын Татарстан Республикасында гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

Татарстан Республикасы икътисадының төрле тармакларында югары белем бирүче мәгариф оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында укучы инвалидларны һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларны алга таба эшкә урнаштыру максатларында максатчан кабул итү һәм максатчан укыту практикасын үстерү (уку вакытында эшкә урнашуны гарантияли торган килешүләр нигезендә потенциаль эш бирүчедә җитештерү практикасын узу белән);

инвалидларның факттагы һәм уңышлы хезмәт интеграциясе мисаллары турында мәгълүмат таратуны тәэмин итү өчен чаралар күрү.

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан бирелә торган инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын эшләү һәм тормышка ашыру тәртибен һәм аларның формаларын раслау турында» 2017 елның 13 июнендәге 486н номерлы боерыгы нигезендә тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында күрсәтелгән һөнәри тернәкләндерү яки абилитацияләү чараларының фаразланган нәтиҗәләре

түбәндәгечә:

һөнәри юнәлеш бирүне гамәлгә ашыру;

укытуны оештыру буенча кирәкле шартлар тудыру; һөнәр (белгечлек) алу (шул исәптән яңа), квалификация күтәрү, һөнәри белем дәрәҗәсен арттыру;

уңайлы эш урыны сайлау;

инвалидны, аның бозылган функцияләрен һәм тереклек эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, эшкә урнаштыру өчен махсус эш урынын җиһазлау (җиһазландыру);

инвалидның хезмәт эшчәнлеге өчен кирәкле шартлар тудыру;

җитештерү адаптациясенә ирешү.

Дәүләт алдында 2020 елга инвалидлыгы булган эшкә яраклы яшьтәге кешеләрнең яртысыннан да ким булмаган өлешен эшкә урнаштыру өчен шартлар тудыру бурычы тора.

Бүген һәр өченче инвалид эшли.

Кайбер каршылыклар һәм, барыннан да элек, эш бирүчеләр тарафыннан инвалидларның хезмәткә хокукын гамәлгә ашыруның мөһимлеген аңлап бетермәү аркасында, эшләргә теләгән күп кенә инвалидларның эшкә урнашырга мөмкинлекләре юк.

Россия Федерациясе Пенсия фонды мәгълүматлары буенча, Татарстан Республикасында 2018 елда эшкә яраклы яшьтәге 53,4 мең инвалид яши, шуларның 20,4 мең кеше (38,2 процент) эшләде, 33,0 мең кеше (61,8 процент) эшләмәде.

2018 елда Татарстан Республикасында инвалидларны хезмәт эшчәнлегенә җәлеп итү буенча системалы эш алып барылды. Халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте тарафыннан эшләмәүче инвалидларның эшкә урнашуга булган ихтыяҗларын ачыклау максаты белән даими режимда сораштыру үткәрелде. 7 меңгә якын инвалид үзләренең эшкә урнашуга теләкләрен белдерде.

Барлык халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә эшкә урнаштыруга мохтаҗ инвалидларны шәхсиләштерелгән исәпкә алу булдырылды. Бу гражданнар белән инвалидларны тернәкләндерү һәм абилитацияләүнең индивидуаль программалары нигезендә аларны эшкә урнаштыру буенча (халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә мөрәҗәгать итүчеләр, шулай ук мөрәҗәгать итмәүчеләр белән дә) адреслы эш алып барылды.

Инвалидларны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү буенча эш (озатып йөрелә торган эш белән тәэмин итүне кертеп) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасы кысаларында гамәлгә ашырыла.

Бу программа кысаларында яшь инвалидлар һөнәри белем алганда һәм алга таба эшкә урнаштырганда аларны озатып йөрү программаларын тормышка ашыру буенча чаралар планы расланды, буш эш урыннарына да, махсус программалар буенча да эш урыннарына эшкә урнаштыруны оештыру буенча чаралар, алга таба аларны эшкә урнаштыру максатларында укыту һәм яңадан укыту, эшмәкәрлек эшчәнлеген оештыруда булышлык итү, квоталана торган һәм резервлана торган эш урыннарына эшкә урнаштыру чаралары һәм башка чаралар тормышка ашырыла.

2018 елда халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына 3 752 инвалид мөрәҗәгать итте, шуларның 1 968е эш белән тәэмин итү органнары ярдәме белән эшкә урнаштырылды, бу мөрәҗәгать иткән инвалидлар саныннан 52,5 процентны

тәшкил итте. 2017 елда 4 351 инвалид мөрәҗәгать итте, 2 522 инвалид, ягъни мөрәҗәгать иткән инвалидларның 58 проценты эшкә урнаштырылды.

2018 елда эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнар өчен махсус программалар кысаларында 786 инвалид эшкә урнаштырылды (вакытлыча һәм җәмәгать эшләре) (2017 елда – 1 655 инвалид).

Республиканың халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарының финанс ярдәме белән 2018 елда 72 инвалид үз эшен ачты, аларга 117,6 мең сум күләмендә финанс ярдәме күрсәтелде (2017 елда – 51 инвалид).

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә ел саен инвалидларны эшкә урнаштыру өчен квота билгеләнә. 2018 елга квота 1 800 эш урынына билгеләнде, 2018 елда аларга 883 инвалид эшкә урнаштырылды (2019 елга квота 1 037 эш урынына билгеләнде, 2019 елның гыйнвар – мартында 202 инвалид эшкә урнаштырылды). 2017 елга квота 1 114 эш урынына билгеләнде, 556 инвалид эшкә урнаштырылды.

2018 елда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан эш урыннарын җиһазлауга (җиһазландыруга) 8,75 млн.сум акча тотылды, аларга 63 эшсез инвалид эшкә урнаштырылды.

Инвалидларның гамәлдәге эш урыннарын саклап калу һәм эшләүче инвалидларның социаль яклануын арттыру максатларында, республиканың халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тарафыннан инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган предприятиеләргә ярдәм күрсәтелә.

Ярдәм предприятиеләрдә инвалидларның эш урыннарын саклап калуга бәйле чыгымнарны каплау максатларында күрсәтелә һәм ул эш бирүче тарафыннан инвалидлар хезмәте өчен түләүгә тотылган чыгымнарны компенсацияләүгә юнәлдерелергә тиеш. 2018 елда бу программада алты предприятие катнашты. Предприятиеләргә хезмәт өчен түләүгә компенсация күчерелгән инвалидлар саны 392 кеше тәшкил итте. 2019 елда инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган предприятиеләрдә эшләүче 377 инвалидка эш урыннарын саклап калу планлаштырыла.

Эшсез инвалидларны эшкә урнаштыру мәсьәләләрен хәл итүдә Татарстан Республикасы «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы белән тәкъдим ителгән бөтен потенциалны куллана

Шул ук вакытта шуны да билгеләп үтәргә кирәк: хәзерге вакытта инвалидларны эшкә урнаштыруның нәтиҗәле системалы эшен оештыруда проблемалы мәсьәләләр бар, аларны организмның төрле функцияләре бозылган инвалидларны укытуның өзлексез белем бирү процессын төзү һәм алга таба эшкә урнаштыру юлы белән (балалар бакчасы – гомуми белем бирү мәктәбе – һөнәри белем бирү – югары белем бирү – халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте, эш бирүчеләр белән үзара хезмәттәшлек итеп, хезмәт базарында фаразланган ихтыяҗны исәпкә алып, эшкә урнаштыру) хәл итәргә мөмкин.

Инвалидларны социаль яклауның өстәмә чаралары түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:

хезмәт базарында әлеге категориядәге гражданнарның көндәлек сәләтен

арттырырга;

эшкә урнаштыру мөмкинлекләрен киңәйтергә һәм инвалидларны, бигрәк тә яшь инвалидларны һәм инвалидлыгын билгеләгәннән соң тернәкләндерелгән инвалидларны эшкә урнаштыру мөмкинлеген тәэмин итәргә;

эш бирүчеләрне инвалидлар өчен эш урыннары булдыруга (җиһазландыруга) стимуллаштырырга;

эшсез инвалидлар өчен эш урыннары булдырырга;

эшсез инвалидларның тормыш дәрәҗәсен күтәрергә.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, тернәкләндерүнең һәм абилитацияләүнең комплекслы системасын формалаштыру һәм үстерү кирәк булачак, инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасының юнәлешләрен билгеләүдә, бу технологиягә аларның гаиләләрен, бу категориядәге гражданнар белән хезмәттәшлек итүче социаль институтларны җәлеп итүдә, шулай ук инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны уңай тормышка урнаштыру максатларында җәмгыять тормышына актив җәлеп итүдә ихтыяҗ туа.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру юнәлешләре төрле яшь төркемнәре инвалидларына, аларның яшәү урыннарына, җәмгыятьтәге активлыгына, ярдәмгә һәм булышуга мохтаҗлыгына карамастан, шулай ук аларның гаиләләренә, аларга ярдәм итүне һәм карауны тәэмин итүче затларга, юридик затларга юнәлдерелгән.

Инвалидларга, шул исәптән инвалид балаларга Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары нормаларында каралган дәүләт ярдәменең төп юнәлешләре лаеклы тормыш дәрәҗәсен, социаль хезмәтләрнең, медицина ярдәменең, мәгълүмат һәм коммуникация технологияләренең һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итүгә, төп һәм өстәмә белем бирү программаларыннан тигез файдалануга, көченнән килгән хезмәт белән тәэмин ителүгә, хезмәт өчен түләү һәм шартлар ягыннан гарантияләргә, мәдәни-ял итү эшчәнлеге, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән хокукый, оештыру һәм икътисадый чаралар системасын үз эченә ала.

Татарстан Республикасында инвалидларны комплекслы тернәкләндерү һәм адаптацияләү проблемалары түбәндәгеләр:

халыкны инвалидлыкка китерүче факторларны бетерүгә юнәлдерелгән профилактика чаралары системасында тагын да нәтиҗәлерәк эшләү зарурилыгы;

федераль дәрәҗәдә бердәм фәнни нигезләнгән стандартларны, тернәкләндерү һәм абилитацияләү хезмәтләре күрсәтү алымнарын һәм стандартларын, субъектларның инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны тернәкләндерүне һәм абилитацияләүне комплекслы күрсәтүнең даимилыгын һәм ведомствоара бәйләнешен норматив-хокукый тәэмин итү формалаштырылмау;

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган инвалидларны карау буенча бердәм стандартлар, технологияләр, аларны Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы яки Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы сайтында урнаштыру, шулай ук медик-социаль экспертиза учреждениеләре һәм башка оешмалар хезмәткәрләрен инвалидлар өчен күрсәтелә торган объектларның һәм хезмәтләрнең һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итү мәсьәләләре буенча укыту (инструкцияләү) өчен методик кулланманы актуальләштерү, «Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә, инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерация-

сенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, учреждениеләр һәм оешмалар хезмәткәрләренә кирәкле ярдәм күрсәтү, укыту, инструкцияләү зарурилыгы билгеләнә (https://rosmintrud.ru/docs/mintrud/handicapped/108);

тернәкләндерү чараларының нәтиҗәлелеген һәм эффектлылыгын бәяләүнең бердәм системасы булмау; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уңайлы мохит» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 29 мартындагы 363 номерлы карары белән расланган «Уңайлы мохит» Россия Федерациясе дәүләт программасының максатчан күрсәткечләре (индикаторлары), Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 10 маендагы б-893 номерлы боерыгы белән расланган 2017 – 2020 елларга инвалидларны эш белән тәэмин итү дәрәҗәсен күтәрү буенча чаралар планы нигезендә тернәкләндерү, «иртә ярдәм күрсәтү» максатына ирешүне исәпкә алып, яшәү урыны буенча үткәрелә торган тернәкләндерү эше нәтиҗәлелегенең унификацияләнгән күрсәткечләре зарурилыгы, сыйфатлы мәктәпкәчә, гомуми, өстәмә белем бирү, һөнәри юнәлеш бирү эше, халыкны эш белән тәэмин итү һ.б. колачлау (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 30 август, 2013 ел, 1014 нче, 2013 ел, 30 август, 1015 нче боерыклары, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2014 ел, 4 август, 515 нче боерыгы). Бу инвалидларны көндезге эш белән тәэмин итәргә, гаиләнең тормыш сыйфатын яхшырту өчен шартлар тудырачак, ата-аналарга һөнәри, хезмәт эшчәнлеге һ.б. белән шөгыльләнү мөмкинлеге бирәчәк;

инвалидларның, шул исәптән инвалид балаларның тереклек эшчәнлегенең төрле өлкәләрендә (сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү, эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтү, мәдәният, спорт һ.б.) хезмәт күрсәтүләргә ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен шартлар булмау һәм инвалидларның (инвалид балаларның) ихтыяҗларын исәпкә алып, тернәкләндерүнең заманча технологияләрен кертү өчен тернәкләндерү чараларын гамәлгә ашыручы оешмаларның матди-техник базасын ныгыту зарурилыгы; инвалидның актив көндәлек тормыш эшчәнлегенә ирешү, алга таба эшкә урнашу белән адекват белем алу, социаль-хезмәт мохитенә интеграцияләү өчен ведомствоара хезмәттәшлек итү дәрәҗәсендә инвалидларны өзлексез этаплап тернәкләндерү системасының дәүләт программасын булдырырга кирәк: сәламәтлек саклау, социаль яклау, мәгариф, мәдәният, спорт һәм эшкә урнаштыру өлкәләрендә.

Ачыкланган проблемаларны хәл итү юнәлешләре:

тернәкләндерү, абилитацияләү чаралары һәм хезмәт күрсәтүләрен уздырганда ведомствоара хезмәттәшлекнең нәтиҗәле механизмын формалаштыру, инвалидның (инвалид баланың) тормыш маршруты дәвамында тернәкләндерү, абилитацияләү чараларының һәм хезмәтләрнең кирәкле төрләрен рациональ һәм сайлап тоташтыру; мәгълүматлар белән ведомствоара алмашу; мәгълүмат системаларын булдыру һәм үстерү һәм аларның үзара интеграциясен тәэмин итү, тернәкләндерү һәм абилитацияләү процессларын мәгълүмати тәэмин итүне үстерү;

инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны тернәкләндерү һәм абилитацияләү өлкәсендә дәүләт хакимияте органнарының һәм социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның үзара хезмәттәшлеге системасын үстерүгә карата таләпләрне билгели торган норматив хокукый базаны камилләштерү;

тернәкләндерү чараларының нәтиҗәлелеген һәм эффективлылыгын бәяләүнең бердәм системасы буенча тәкъдимнәр кертү;

инвалидлар, шул исәптән инвалид балалар өчен тернәкләндерү һәм абилитацияләү чараларын гамәлгә ашыручы белгечләрне әзерләү һәм аларның квалификациясенн күтәрү системасын формалаштыру;

инвалидны гына түгел, аның гаилә әгъзаларын да тернәкләндерү процессына актив җәлеп итү;

инвалидларның (инвалид балаларның) ихтыяҗларын исәпкә алып, тернәкләндерүнең заманча технологияләрен кулланышка кертү өчен тернәкләндерү чараларын гамәлгә ашыручы оешмаларның матди-техник базасын ныгыту.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәсе булып инвалидларның, шул исәптән инвалид балаларның актив тормышы өчен шартлар тудыру, алар бу категориядәге гражданнарның һәм аларның гаиләләренең тормыш дәрәҗәсен һәм аның сыйфатын яхшыртырга мөмкинлек бирәчәк.

## II. Ярдәмче программаның максаты, бурычлары һәм максатчан күрсәткечләре (индикаторлары)

Ярдәмче программаның максаты – Татарстан Республикасында инвалидларның, шул исәптән инвалид балаларның тернәкләндерү һәм абилитацияләү хезмәтләре, иртә ярдәм күрсәтү белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен, шулай ук инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны (эш белән тәэмин итүдә ярдәм итүне кертеп) һөнәри үсеш һәм эш белән тәэмин итү дәрәҗәсен күтәрү.

Ярдәмче программаның бурычлары:

Татарстан Республикасында инвалидларның, шул исәптән инвалид балаларның тернәкләндерү һәм абилитацияләү хезмәтләре күрсәтүгә, иртә ярдәм күрсәтү хезмәтләренә булган ихтыяҗын билгеләү;

Татарстан Республикасында инвалидларның, шул исәптән инвалид балаларның һөнәри үсеше һәм эш белән тәэмин ителеше (эш белән тәэмин итүдә ярдәм ителә торган булышлык күрсәтүне кертеп) дәрәҗәсен күтәрү өчен шартлар тудыру;

Татарстан Республикасында инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү, шулай ук иртә ярдәм күрсәтү системасын оештыру буенча норматив хокукый һәм методик базаны формалаштыру һәм актуаль хәлдә тоту;

Татарстан Республикасында инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү, шулай ук иртә ярдәм күрсәтү системасын, үстерү өчен шартлар булдыру;

инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү, шулай ук иртә ярдәм күрсәтү программасын гамәлгә ашырганда ведомствоара хезмәттәшлекне оештыру;

тернәкләндерү һәм абилитацияләү хезмәтләре күрсәтүдән һәркем файдалана алуны арттыру һәм аларның сыйфатын яхшырту.

Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2020 ел йомгаклары буенча Ярдәмче программаны тормышка ашыруны характерлый торган түбәндәге төп күрсәткечләрне арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

тернәкләндерүнең һәм (яки) абилитацияләүнең индивидуаль программасында

тернәкләндерү һәм (яки) абилитацияләү чараларын гамәлгә ашыру турында тәкъдимнәре булган Татарстан Республикасы инвалидларының гомуми санында әлеге чаралары гамәлгә ашырылган инвалидлар өлешен 71,9 процентка кадәр;

тернәкләндерүнең һәм (яки) абилитацияләүнең индивидуаль программасында тернәкләндерү һәм (яки) абилитацияләү чараларын гамәлгә ашыру турында тәкъдимнәре булган Татарстан Республикасы инвалид балалаларының гомуми санында әлеге чаралары гамәлгә ашырылган инвалид балалар өлешен 73,8 процентка кадәр;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан тернәкләндерү оешмаларының гомуми санында инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү яки абилитацияләүнең төбәк системасына кертелергә тиешле тернәкләндерү оешмалары өлешен 48 процентка кадәр;

Татарстан Республикасы чыгарылыш сыйныф инвалид укучыларының гомуми санында һөнәри юнәлеш бирү эшенә җәлеп ителгән 9 нчы һәм 11 нче сыйныфларның чыгарылыш инвалид укучылары өлешен 100 процентка кадәр;

Татарстан Республикасында эшкә яраклы яшьтәге инвалидларның гомуми санында эшкә яраклы яшьтәге инвалидларның эш белән тәэмин ителгән өлешен 50* процентка кадәр;

хисап чорында инвалидларны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программаларыннан өземтәләр рәвешендә мәгълүматлары Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү органнарына кертелгән эшкә урнаштыруга мохтаҗ булган Татарстан Республикасы инвалидларының гомуми санында эшкә урнаштырылган инвалидлар өлешен 60* процентка кадәр;

Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү органнарына мөрәҗәгать иткән һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучы инвалидларның гомуми санында эшкә урнаштырылган инвалидлар өлешен 75* процентка кадәр;

беренче тапкыр инвалид дип танылган һәм Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән Татарстан Республикасы гражданнарының гомуми санында эшкә урнаштырылган инвалидлар өлешен 80* процентка кадәр;

иртәрәк ярдәм күрсәтү хезмәтләренә мохтаҗ Татарстан Республикасы балаларының гомуми санында әлеге хезмәтләрдән файдаланган максатчан төркемдәге балалар өлешен 40 процентка кадәр;

Татарстан Республикасында иртәрәк ярдәм күрсәтү программаларына кертелгән, иртәрәк ярдәм күрсәтү хезмәтләренең сыйфатыннан канәгать булган гаиләләр өлешен 90 процент кадәр;

Татарстан Республикасында инвалидларга, шул исәптән инвалид балаларга тернәкләндерү һәм (яки) абилитацияләү чаралары күрсәтүне тәэмин итүче, квалификация күтәрү һәм белгечләрне һөнәри яңадан әзерләү программалары буенча, шул исәптән инвалидларны тернәкләндерү һәм абилитацияләү

---

* Фараз күрсәткечләренә төзәтмәләр хезмәт базарындагы киерен-келекне, инвалидларны эшкә урнаштыру (эшкә урнаштырганда яшь инвалидларны озатып йөрү программаларын тормышка ашыру йомгакларын кертеп) динамикасын, инвалидларның эшкә урнашуга ихтыяҗлары, квота буенча файдалану мөмкинлеге булган эш урыннары саны турындагы статистика мәгълүматларын исәпкә алып кертелергә тиеш.

методикаларын куллану буенча белем алган белгечләрнең Татарстан Республикасында әлеге белгечләрнең гомуми санындагы өлешен 45 процентка кадәр;

бергә яшәү белән тәэмин итела торган инвалидларны колачлауны 40 кешегә кадәр.

2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасының 2020 елга каралган өлешендә 2019 – 2022 елларга «Инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасын формалаштыру» ярдәмче программасының эшләнгән проекты кысаларында Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 14 октябрендәге 13-5/10/П-9148 номерлы хаты нигезендә белдерелгән федераль бюджеттан финанслау күләме 38 968,10 мең сум, шул исәптән: Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 16 366,6 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 22 601,5 мең сум тәшкил итә.

Программаның төп чаралары итеп түбәндәгеләр билгеләнде:

комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасында эшләүче белгечләрне укыту;

тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтүче учреждениеләрне тернәкләндерү җиһазлары белән тәэмин итү;

комплекслы тернәкләндерүне һәм абилитацияләүне тормышка ашыруга системалы якын килүне формалаштыру өчен норматив хокукый һәм методик базаны әзерләү һәм апробацияләү.

Комплекслы якын килүне тәэмин итү буенча төп чара булып инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасын формалаштыру, инвалидларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләүдә катнашучы тернәкләндерү учреждениеләренең ведомствоара хезмәттәшлеген үстерү тора (шул исәптән халыкны социаль яклау, гражданнарның сәламәтлеген саклау, физик культура һәм спорт, мәгариф, мәдәният, халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү өлкәсендә, шулай ук Социаль иминият фонды һәм Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль бүлекчәләре белән хезмәттәшлек итү).

2019 – 2022 елларга максатчан күрсәткечләр (индикаторлар) турындагы мәгълүматлар бу Ярдәмче программага теркәлгән 1 нче кушымтада китерелгән.

2019, 2020, 2021, 2022 елларга Ярдәмче программа чаралары исемлеге һәм чаралар буенча финанслау бу Ярдәмче программага теркәлгән 2, $2^1$ нче кушымталарда китерелгән.

## III. Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары 2019 – 2022 елларга билгеләнгән.

## IV. Ярдәмче программа чаралары исемлеге

Ярдәмче программа чаралары исемлеге бу Ярдәмче программага теркәлгән 2, $2^1$, $2^2$, $2^3$ нче кушымталарда китерелгән.

## V. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителеше

2019 – 2022 елларга Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 162 677,8 мең сум тәшкил итә, шул исәптән: Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 67 553,1 мең сум; федераль бюджет акчасы исәбеннән – 95 124,7 мең сум. Шулардан 2020 елга Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 38 968,1 мең сум тәшкил итә, шул исәптән: Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 16 366,6 мең сум; федераль бюджет акчасы исәбеннән – 22 601,5 мең сум.

Татарстан Республикасында 2019 – 2022 елларга Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителеше күләме бу Ярдәмче программага теркәлгән 3 нче кушымтада китерелгән.

Татарстан Республикасында инвалидларны, инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерүне һәм абилитацияләүне тормышка ашыру чараларын ресурслар белән тәэмин ителешен якынча бүлү турындагы мәгълүматлар, шул исәптән 2019, 2020, 2021, 2022 елларга Ярдәмче программа кысаларында (Татарстан Республикасында гамәлдә булган дәүләт программаларын исәпкә алып) бу Ярдәмче программага теркәлгән 4, $4^1$ нче кушымталарда китерелгән.

2019, 2020, 2021, 2022 елларга Ярдәмче программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм чаралар буенча финанслау бу Ярдәмче программага теркәлгән 5, $5^1$ нче кушымталарда китерелгән.

## VI. Ярдәмче программаны тормышка ашыруны тикшерүдә тоту һәм идарә итү

Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмы Ярдәмче программа чараларын, финанслау күләмнәрен һәм чыганакларын планлаштыруны, максатчан индикаторларга ирешүне фаразлауны, Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыруны, максатчан индикаторларга ирешү максатларында Ярдәмче программаны үтәү барышын мониторинглауны һәм тикшерүдә тотуны үз эченә ала.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру гамәлдәге законнар нигезендә Ярдәмче программа чараларын үтәүчеләр тарафыннан төзелә торган дәүләт ихтыяҗлары өчен продукция сатып алуга һәм кайтартуга дәүләт контрактлары (шартнамәләр) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру өчен кирәкле идарәчел карарлар кабул итү, норматив хокукый актларны раслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Ярдәмче программаның дәүләт заказчысыннан – координаторыннан кергән мәгълүматны исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы – координаторы булып Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тора.

Ярдәмче программаның дәүләт заказчылары – үтәүчеләре:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы;

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы;

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы.

Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы – координаторы аны тормышка ашыру барышында:

Ярдәмче программа белән җитәкчелек итүне һәм аны тормышка ашыру белән агымдагы идарә итүне гамәлгә ашыра;

Ярдәмче программаны тормышка ашыру кысаларында Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, инвалидларның иҗтимагый оешмалары эшчәнлеген координацияли;

үз компетенциясе кысаларында Ярдәмче программаны тормышка ашыру өчен кирәкле норматив хокукый актлар проектларын эшли;

Ярдәмче программа нәтиҗәлелегенең максатчан күрсәткечләре мәгънәләренә ирешүне тәэмин итә;

сан-сыйфат күрсәткечләрен һәм чараларны үтәү яки үтәмәү тасвирнамәсен үз эченә алган чараларның үтәлеше турындагы мәгълүматларны күрсәтеп, Ярдәмче программа чараларының үтәлеше турындагы хисап мәгълүматын квартал саен (хисап кварталыннан соң килә торган айның 15еннән дә соңга калмыйча) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына федераль бюджеттан субсидия бирү буенча имзаланган килешү нигезендә билгеләнгән форма буенча һәм вакытларда кертүне гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының мәгълүматларын исәпкә алып, Татарстан Республикасы тарафыннан финанс йөкләмәләре үтәлүе турында, шул исәптән Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары, Ярдәмче программаның максатчан күрсәткечләренең ирешелгән мәгънәләре турында хисаплар кертүне гамәлгә ашыра;

товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказларны Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә урнаштыруны һәм тиешле контрактлар төзүне тикшерүдә тотуны тәэмин итә;

ел саен Ярдәмче программаны тормышка ашыру барышы турында һәм аның нәтиҗәлелеген бәяләү хакында доклад әзерли;

Ярдәмче программаны тормышка ашыру барышы һәм аның нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны электрон рәвештә урнаштыруны оештыра;

Ярдәмче программаны тормышка ашыру барышын яктырту мәсьәләләре буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итә.

Кирәк булганда, Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы – координаторы Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытын озайту турында Татарстан Республикасы норматив хокукый акты проектын эшләүне тәэмин итә.

Түбәндәге өлкәләр буенча Ярдәмче программаның җаваплы үтәүчеләре, Татарстан Республикасының вәкаләтле башкарма хакимият органнары, чараларны тормышка ашыру өчен җаваплылар:

сәламәтлек саклау өлкәсендә – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы;

мәгариф өлкәсендә – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

физик культура һәм спорт өлкәсендә – Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы;

мәдәният өлкәсендә – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы;

мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә – Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы; Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хисап палатасы субсидияләрне максатчан, адреслы һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

Ярдәмче программа чараларын башкару өчен җаваплы үтәүчеләр:

Ярдәмче программа чараларының үтәлешен һәм алар карамагындагы тармак чараларына карата аларның үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

финанслау күләмнәрен җиткерү өчен, айларга таркатып һәм финанслауның максатчан кодларын күрсәтеп, Ярдәмче программаның координаторына кварталга ихтыяҗ турында мәгълүмат бирә (планлаштырыла торган кварталның беренче аендагы 10ысына кадәр);

Ярдәмче программаның һәр чарасы буенча эшләр башкаручыларны һәм хезмәт күрсәтүчеләрне, шулай ук продукция белән тәэмин итүчеләрне конкурс нигезендә сайлап алуны гамәлгә ашыра;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 10ысыннан да соңга калмыйча, Ярдәмче программаны тормышка ашыру буенча чыгымнарны гамәлгә ашыру турындагы хисапны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына билгеләнгән тәртиптә җибәрә;

квартал саен Ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәләрен гомумиләштерә һәм анализ ясый һәм хисап кварталыннан соң килә торган айның 10сына кадәр аны тормышка ашыруның барышы турындагы мәгълүматны дәүләт заказчысына – Ярдәмче программаның координаторына җибәрә.

Инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасын формалаштыру чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасын формалаштыру чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләрен раслау турында» 2019 ел, 13 июль, 582 нче карары белән расланган. Кагыйдәләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган, инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасын формалаштыру чараларын тормышка

ашыруга юнәлдерелгән «2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү механизмын билгели.

Инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасын формалаштыру чараларын үз эченә алган дәүләт программасын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты акчасы һәм әлеге чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субсидияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы түбәндәгеләрне Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына кертә:

ел саен, хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварына кадәр, федераль бюджет субсидияләрен файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турындагы хисапны иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең «Электрон бюджет» дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасындагы электрон документ рәвешендә;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15еннән дә соңга калмыйча, федераль бюджеттан финанслашу максаты белән субсидия бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турындагы хисапны иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең «Электрон бюджет» дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасындагы электрон документ рәвешендә. Хисаплар Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Россия Федерациясе субъекты бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр бирү турындагы килешүнең бертип формасын раслау хакында» 2018 елның 14 декабрендәге 269н номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе субъекты бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр бирү турындагы килешүнең бертип формасына 10 нчы һәм 11 нче кушымталары нигезендәге форма буенча тапшырыла.

Федераль бюджеттан бирелгән субсидияне максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында гамәлгә ашырыла.

## VII. Ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү

Ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасында инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү, иртә ярдәм күрсәтү системасын камилләштерү өчен шартлар тудыру;

Татарстан Республикасында инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү, иртә ярдәм күрсәтү өчен шартлар булдырганда ведомствоара хезмәттәшлекне һәм эшләрне координацияләүне тәэмин итү;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру максаты белән Татарстан Республикасында инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны

комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү, иртә ярдәм күрсәтү системасын камилләштерү турында мәгълүмат җыю, системалаштыру;

инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны уңышлы тернәкләндерү яки абилитацияләү һәм социальләштерү өчен шартлар булдыру.

Татарстан Республикасында инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү, иртә ярдәм күрсәтү системасын камилләштерү өлешендә законнарның үтәлешенә мониторинг һәм контроль системасын булдыру, Ярдәмче программаның хокукый норматив, методик характердагы чараларын гамәлгә ашыру инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү яки абилитацияләү, иртә ярдәм күрсәтү хезмәтләре белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Ярдәмче программаның гамәли чараларын тормышка ашыру түбәндәгеләргә булышлык күрсәтәчәк:

Татарстан Республикасында инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү, иртә ярдәм күрсәтү системасын камилләштерүгә;

инвалидларның, шул исәптән инвалид балаларның һәм аларның гаиләләренең тормыш дәрәҗәсен күтәрүгә һәм сыйфатын яхшыртуга;

инвалидларның, шул исәптән инвалид балаларның социаль бәйлелеген киметүгә, аларның көндез эш белән тәэмин ителешен арттыруга;

инвалидларның, шул исәптән инвалид балаларның социаль һәм һөнәри активлыгын стимуллаштыруга;

паралимпия, сурдолимпия, парадельфия хәрәкәтләрен, экскурсия туризмын үстерүгә.»;

Ярдәмче программага теркәлгән 1, 2, $2^1$, 3, 4, $4^1$, $5^1$, 6 нчы кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә;

Ярдәмче программага $1^1$, $2^2$, $2^3$, $4^2$, $4^3$, $5^2$, $5^3$ нче кушымталарны (карарга теркәләләр) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин